Салават Фәтхетдинов:
«Популярлык миннән мәңге китмәячәк»

«Популярлык минем белән гомерлеккә, чөнки ат кебек эшлим, үз йөгемне ат кебек тартам. «Салават» эстрада театры – бүгенге көндә гастрольләрдә иң күп йөри торган төркем. Мактанып әйтүем түгел, бу, киресенчә, сәламәтлеккә тискәре йогынты ясый. Әллә инде берәр ел ял итеп торыйм микән дигән уйлар да бар – туктап торырга ярамый».

12 БИТ

Фазыловларның биш шатлыгы

Фазыловлар гаиләсе өчен бу ел бигрәк тә үзенчәлекле. Ай ярым элек кенә аларның игезәк балалары Хәким белән Хания туды. Раил, Илназ һәм Ясминә берьюлы энеле дә, сеңелле дә булдылар.

8 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 9.03.2017 | № 24 (5786)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ һӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

БЕРЕНЧЕ

Казан вертолет заводы тарихында беренче хатын-кыз баш металлург Марина Ожегова: «Баштарак үземне космоска очкан Валентина Терешкова кебек хис итә идем», – дип елмая. Металлургия өлкәсендә, гадәттә, ир-атлар хезмәт итсә дә, язмабызның каһарманы бу һөнәрне сайлавына һич кенә дә үкенми. Аныңча, һәр эш үзенчә кирәкле.

10 БИТ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Реклама

П2430 Атналык (пәнҗешәмбе)

1 айга 66 сум 99 тиен
3 айга 200 сум 97 тиен
6 айга 401 сум 94 тиен

Ташламалы бәядән язылып кал!

һәр айның 15 числосына кадәр язылсагыз, газета киләсе ай башыннан киләчәк.

Синең өчен, синең турында!

П2395 Көндәлек (сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)

136 сум 15 тиен 1 айга
408 сум 45 тиен 3 айга
816 сум 90 тиен 6 айга

РЕСПУБЛИКАДА

ЯШЕЛ ҮЗӘН

Яшел Үзәндә «Имин» шәһәр муниципаль программасы эшли башлаячак. Ул Мәскәүдә, шулай ук Россиянең башка күп кенә шәһәрләрендә гамәлдә. Бүгенге көндә замана җиһазы – яңа буын домофонын урнаштыручылар «аның өчен абонент түләве аена 45-50 сум тирәсе булыр» дип фаразлый. Ә аны дүрт каттан да биегрәк йортларга урнаштыру бөтенләй дә бушлай булачак.

ЧАЛЛЫ

Шәһәрдә беренче тапкыр Студент һәм укучы яшьләрне эшкә урнаштыру үзәге ярдәме белән студентларның хезмәт отрядлары төзелә башлады. Студентларны күбрәк акчалы хезмәтләр җәлеп итә. Алар арасында Ерак Көнчыгышка балык эшкәртү комбинатына эшкә барырга теләүчеләр шактый икән.

ЗӘЙ

Зәйдә Татарстанның һөнәри белем бирү уку йортлары укучылары арасында узган спартакиаданың финал ярышлары үтте. Өч көн дәвамында 500дән артык спортчы баскетбол, алкалы хоккей, өстәл теннисы һәм чаңгыда узышу буенча шәхси һәм команда беренчелеге өчен ярыштылар.

АКСУБАЙ

Районда Бөтенроссия авыл хуҗалыгын исәпкә алуда катнашучыларны бүләкләделәр. Исәпкә алу кампаниясендә катнашкан ун кешегә Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең «Бөтенроссия авыл хуҗалыгын исәпкә алуны үткәрүдәге башкарган эшләр өчен» медаленә лаек булды.

ЛЕНИНОГОРСК

Лениногорскида коткаручылар оныгы балконда бикләп калдырган өлкән яшьтәге хатын-кызны коткарган. Өч яшьлек малай 72 яшьтәге әбисен балконда бикләп калдырган. Әби кеше фатирга балалар янына коткаручылар ярдәмендә генә керә алган. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре фатир ишеген ачып кереп, әби-карчыкны балконнан чыгарган. Бу вакытта фатирда шук малай белән аның бер яшьлек сеңлесе дә булган.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды.

«Хатын-кызларсыз булмый»

«Бәйрәм алдыннан очрашу кулай булыр дип уйладык» – Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов 8 март алдыннан хатын-кыз журналистлар белән очрашуны шул сүзләрдән башлады. «Сөйләшер сүзләр дә артып китте соңгы арада», – дип өстәде аннары үзгә интонация белән һәм бу сүзләргә аерым мәгънә салып.

tatarstan.ru

Сөйләшер сүзләрнең нинди булуы аңлашыла анысы: бу арада бөтен сөйләшкәнебез – «Татфондбанк»ка бәйле рәвештә банк секторындагы вазгыять. Президентның бу сорауга җавабын 5нче биттән укыгыз. Сүз уңаеннан, аның ни дәрәҗәдә борчылуы йөзенә язылган иде. Шулай да ул әледән-әле елмайды һәм гүзәл затларны чәй эчәргә, капкалап утырырга кыстады. Чәй табынын матур әзерләткәне өчен, аппарат җитәкчесе Әсгать Сафәровка мактау сүзләре дә тапты: «Лаеклы булган бу», – ди.

«Шәһри Казан» газетасының соравыннан Президент уйга калды.

– Юбилеегыз уңаеннан котлаулар татарстанлыларның сезне ни дәрәҗәдә яратуын күрсәтте. Мәхәббәт ул – ышаныч, ышаныч исә җаваплылык дигән сүз. Шушы җаваплылык йөге ни дәрәҗәдә авыр һәм Президент булу холкыгызга тагын нинди сыйфатлар өсти? – дип сорадык.

Бераз уйланып алганнан соң:

– Республиканы яратырга кирәк! – диде Рөстәм Нургалиевич. – Халыкны яратырга! Эшеңне яратырга һәм бик күп эшләргә кирәк. Шул очракта гына нинди дер нәтиҗә булачак. Әгәр син җитәкче булыр өчен генә йөрисең икән, эшеңнең нәтиҗәсе булмаячак. Шуңа күрә беренче чиратта республикага, халыкка хезмәт итәргә кирәк. Барысы да син уйлаганча бармаячак, тик барып чыксын өчен тырышырга кирәк. Тырышсаң – була. Республиканың потенциалы бик зур.

Президент командасында хатын-кызларның зур роль уйнаганын да белдек.

– Хатын-кызларсыз мөмкин түгел, – диде ул. – Сүз дә юк, ир-ат җитәкче булырга мөмкин, әмма аннан соң хатын-кызлар булмаса – бетте. Президент аппаратының 46 проценты – хатын-кызлар. Хөкүмәттә дә шуннан азрак түгелдер дип уйлыйм. Беренче позицияләрдә хатын-кызлар азрак, анысы – икенче мәсьәлә. Гомумән, алар йөкләмәләргә җаваплырак карый, эшкә. Ир-атлар бит оныталар. Берәр яхшы вакыйга була да, кушканны онытып җибәрәләр. Шуңа күрә без хатын-кызларга таянабыз. Коллективта, һичшиксез, хатын-кызлар булырга тиеш. Алар, чыннан да, ирләргә караганда җаваплырак.

Рөстәм Миңнеханов шулай ук аның социаль челтәрләренә килгән сорау-гозерләрнең «Халык контроле» сисемасына кертеләчәген хәбәр итте. Сүз уңаеннан, Президент Инстаграмдагы битендә һәркөнне хәерле иртә тели. Ә һәрбер фотосы астына берничә сорау языла.

– Аларны укуы һәрвакытта күңелле түгел, – дип ачылды республика җитәкчесе. – Син хәерле иртә телисең, ә сиңа… Тик һәр кешенең моңа үз аңлатмасы бар. Бездә «Халык контроле» системасы эшли. Менә мин йөкләмә бирдем. «Халык контроле» хезмәтендәге коллегаларым ул сорауларны контрольгә куячак. Исемле булса, мөрәҗәгатьләргә җавап бирәчәкләр.

Рөстәм Миңнеханов шулай ук яр буйларын төзекләндерү, урманнарны чистарту, мәктәп һәм сырхауханәләр төзү сорауларына да тукталды.

КАЗАНЫШЛАРЫ ӨЧЕН – ОРДЕН

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Александр Невский ордены белән бүләкләнгән. Россия Президенты Владимир Путин бүләкләнү турында 1 мартта ук кул куйган документта, ил алдындагы шәхси казанышлары һәм Россиянең халыкара абруен ныгытуга зур өлеш керткәне өчен Рөстәм Миңнехановны Александр Невский ордены белән бүләкләргә, диелгән.

Шәһәр кәефе

НИЯЗ ШӘЙДУЛЛИН,
умартачы:

– Бездә кыш чоры озынрак шул. Җәй сагындырды. Умартачылык белән шөгыльләнәм. Бал кортлары алар бик тырыш һәм бик пөхтә җан ияләре. Уңыш аласың килсә, үзеңә дә эшләргә кирәк. Төп юаныч, әлбәттә инде, балалар. Алар тизрәк үссеннәр, дип йөгерәбез баштa, аннан соң исән-сау яшәсеннәр, дип телибез. Дөньяда тынычлык булсын! Мин бүгенге тормыштан канәгать.



ЛӘЙСӘН САФИНА,
«Идел» яшьләр үзәге җитәкчесе:

– Шөкер, бүген мине берни борчымый. Яраткан кешем, гаиләм бар, туганнарым сау-сәламәт, кызыклы эшем, дусларым янәшәмдә. Дөньяның матурлыгын күрә белү – үзе зур бәхет! Инде менә язга кердек. Меңьеллык шәһәрнең үз моңы, үз холкы бар. Аның сулышын тою, урамда йөрүче балаларны, яшьләрне, туристларны күзәтү күңелле. Яз яңа идеяләргә, кызыклы очрашуларга бай булырга охшаган. Урамнан барганда бер-беребезгә дустанә елмаерга онытмыйк!

ВАЛЕРИЯ НЕСТЕРОВА,
хезмәткәр:

– Казанда туып-үстем, шәһәрем белән горурланам. Европа илләреннән килгән кешеләр бездәге яхшы спорт сарайларын күреп шаккаты. Казанның аурасы, рухы җиңел дип әйтәләр. Җәйге сәяхәтләрне яратам. Җиде илдә булдым. Шулар арасыннан АКШ белән Германия күбрәк ошады. Алардагы кешеләр дә ярдәмчел. Чираттагы ялымда Грециягә барырга дип хыялланам. Әдәби әсәрләрне компьютердан түгел, ә китаптан укыйм.

ИЛГИЗӘ ЛОТФУЛЛИНА,
пенсионер:

– Чаллыда яшибез. Казанга килгәләп йорибез, чөнки улыбыз Булат шушында укый. Заманында үзем дә Актаныш районыннан килеп, КФУның татар теле бүлеген тәмамлаган идем. Инде улым да үзем йөргән сукмаклардан атлый. Моның белән бик горурланам. Бу арада бик олы сөенечебез бар, кызыбыз Айсылуның улы туды. Казанга бәби алырга килдек. Бәхетле, игелекле сабый булсын!

АЙРАТ ӘМИНОВ,
журналист:

– Спортның көрәш төрен яратам. Әтием Рамазан Апас районының Байраш авылы Сабан туйларында берничә ел батыр булып калды. Әнием Гөлсемнең әтисе дә көрәшче иде. Көрәшкә хирыслык миңа әти белән бабайдан күчкәндер, мөгаен. Казанда шәһәр читендә автомобиль куеп калдыру мәйданнары яки корылмалары төзесеннәр иде. Шәһәр үзәгендәге парковкалар бәяләре авыллардан йомыш белән килгән кешеләр өчен бик кыйммәт.

Иркәләнеп яшәгез!

Россиялеләрнең яртысы, ир-атларга караганда, хатын-кызларга яшәү авыррак, дип саный. «Җәмәгатьчелек фикере» фонды илнең 53 төбәгендә 104 торак пунктта 1500 респондент арасында сораштыру үткәргән. Россиядә ир-атларга яшәү авыррак дип белдерүчеләр 9 процент кына булган.

aif.ru

Респондентларның 35 проценты «Россиядә хатын-кызларга һәм ир-атларга яшәү авырлыгы бертигез» дигән фикердә. Ә 48 проценты «хатын-кызларга яшәү авыррак» дигән фикердә тора. Алар моны өй мәшәкатьләре һәм балалар тәрбияләү хатын-кыз җилкәсенә күбрәк төшүе (18 процент), гаилә өчен җаваплылык булуы (9 процент), эш табу кыенлыгы (7 процент) белән аңлата. Сүз уңаеннан, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Метроэлектротранс» коллективы хатын-кызлары белән очрашуда: «Эштән кала, сезнең башка мәшәкатьләрегез, гаилә, ирләрегез, балаларыгыз бар, әмма сез барысына да өлгерәсез. Минемчә, кайдадыр нәрсәдер килеп чыкмый икән, бу эшне хатын-кызга тапшырырга кирәк. Әгәр дә ул да булдыра алмаса, димәк, бу эшләрлек эш түгел», – дигән иде.

Ләйлә ДӘҮЛӘТОВА, шагыйрә:

– Миңа калса, ир-ат булу авыррак. Аның өстендә акча эшләү, гаиләне матди яктан тәэмин итү бурычы тора. Гаиләсе өчен ул – җаваплы кеше. Ә хатын-кыз өстендә – өй эшләре, бала тәрбияләү. Бу – күпкә рәхәтрәк, кызыграк вазифа. Шуны тоеп яшәгән хатын-кыз бәхетле дә инде. Күп кенә хатын-кызлар карьера артыннан куа, ирләренә баш булырга омтыла, менә шундыйлар аннары, хатын-кызга авыррак, дип зарлана. Гүзәл затлар иркәләнеп, сөелеп яшәргә тиеш ләбаса.

Камил КӘРИМОВ, язучы:

– Безнең илдә хатын-кызга яшәү чынлап та авыррак. Бу беренче чиратта эш табуда чагыла. Алар бөтен җиргә дә эшкә урнаша алмый. Кыскартылуга эләккән кешеләр арасында да эш таба алмыйча интегүчеләр, нигездә, хатын-кызлар. Ир-атлар акча үлмәс өчен, гаиләсен акчасыз калдырмас өчен, теләсә кая эшкә урнаша ала. Физик чыдамлылык таләп ителгән эштә, хатын-кызлар никадәр сабыр, түзем булса да, ирләр генә эшли ала.

Илдар КЫЯМОВ,
«ТНВ» алып баручысы:

– Бу дөньяда беркемгә дә яшәү җиңел түгел. Статистика буенча бездә хатын-кызлар ир-атлардан күбрәк. Бер иргә ун хатын-кыз туры килә, диләр. Шаккаткыч: чибәр, мөлаем кызлар күп, ә ирләре юк. Андыйлар дөньяны үзләре генә алып бара, машинасын да йөртә, күп акчалы эшкә дә урнаша. Ялгызлары бала да үстерә. Көне-төне чабалар, дөнья куалар. Ничек итеп аларга яшәү ансат дип әйтеп була инде монда?

Эзләренә төштеләр

Февраль урталарында Казанның Гадел Кутуй урамындагы 1нче йорт янында Казан федераль университетының юридик факультетында укучы Африка студентының үле гәүдәсе табылган иде. Аның гәүдәсен төнлә очраклы рәвештә үтеп баручылар күргән. Яшь егет күпсанлы пычак яраларыннан үлгән.

Чад Республикасының 24 яшьлек студентының үле гәүдәсе табылу буенча җинаять эше кузгатылды. Татарстан прокуратурасы әлеге эшне аерым контрольгә алды. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та Африка студентын үтерүчеләр турындагы мәгълүмат өчен 1,5 миллион сум акча түләнәчәк дип белдерде. Шушы көннәрдә полициянең җинаятьчеләрне эзләү бүлеге хезмәткәрләре чит ил студентын үтерүдә шикләнелүче ике кешене тоткарлаганнар, дип хәбәр итә Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәте. Алардан алынган мәгълүмат буенча, тоткарланучыларның икесе дә – скинхедлар. Хәзерге вакытта алар белән тикшерүчеләр эшли. 22 яшьлек Руслан Архипов (элеккеге фамилиясе – Хиалеев) белән 19 яшьлек Роман Хәлилов үзләренең гаебен таныган. Алар элек тә җинаять җаваплылыгына тартылган булган. Берсе белә торып кеше сәламәтлегенә зыян салган өчен җаваплылыкка тартылган, икенчесе социаль челтәрдәге битендә экстремистик материаллар урнаштырган булган.

ТОП – 5

АНА КАПИТАЛЫН алу гаризасын карау вакыты ун көнгә кадәр кыскартылды, дип хәбәр итә Россия Пенсия фонды идарәсенең Казан шәһәре Вахитов районындагы бүлеге белгечләре. Моңа кадәр гаризалар ай дәвамында өйрәнелгән.

Сүз уңаеннан, 1 мартта Россия Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы ана капиталы программасын 2023 елга кадәр озайтырга тәкъдим итте.

Узган елның декабрендә Россия Президенты Владимир Путин ана капиталы күләмен 2020 елның 1 гыйнварына кадәр 453 мең сум күләмендә калдыру канунын имзалады.

РОСПОТРЕБНАДЗОР Санитар кагыйдә һәм нормаларның (СанПиН) «Хатын-кызның хезмәт шартларына санитар-эпидемиология таләпләре» проектын әзерләгән, дип яза «Татар-информ». Яңа таләпләр буенча, бала көткән хатын-кызларны табигый яктылык төшмәгән биналарда эшләтү тыела. Шулай ук эш бирүче яшь ярымга кадәрге баласы булган хатын-кызларны бала ашату өчен махсус җиһазландырылган бүлмә белән дә тәэмин итәргә тиеш. Анда өстәл, урындык, ятакчык, баланы биләүгә төрү өчен өстәл, унитаз һәм җылы су килгән юыну урыны булырга тиеш. Яңа санитар кагыйдә һәм нормалар бу ел дәвамында үз көченә керергә тиеш.

ПОЛИЦИЯ хезмәткәрләре Казанда яңа туган баласын чүп савытына ыргыткан дип фаразланылган бер хатынны кулга алганнар, дип хәбәр итә «Татар-информ». Тоткарланган хатын – Үзбәкстан гражданы, 29 яшендә. Алдарак әйтеп узганча, ул бала җәсәде табылган урыннан ерак түгел генә бер йортта яши ди. Исегезгә төшерәбез, 27 февральдә урам җыештыручы Габишев урамының 35нче йорт янындагы чүп җыю мәйданчыгындагы чүп савытыннан яңа туган бала гәүдәсенә тап була.

МИНИСТРЛАР кабинеты 2017 елда авылда торак квадрат метры бәясен раслады. «Татарстанда 2017 елга социаль түләү күләме хисабыннан авылда торак квадрат метры бәясен раслау турында»гы карар нигезендә, авылда яшәүче яки яшәргә һәм эшләргә кайтырга теләк белдергән яшь гаиләләр, яшь белгечләргә торак төзелешенә яки сатып алуда дәүләт ярдәме квадрат метрга 24,3 мең сум исәбеннән булачак.

СОЦИАЛЬ объектларны капиталь төзекләндерү программасы кысаларында быел Казанда 12 мәктәп һәм тугыз балалар бакчасын төзекләндерү планлаштырыла. Моның өчен 526 миллион сум акча каралган. Шулай ук 43,2 миллион сумга сигез үсмерләр клубы рәткә китереләчәк. Болардан тыш башкалада 224 күпфатирлы йортның да капиталь төзекләндерү ниятләнелә. Бу максатларда 1,5 млрд сум акча бүлеп бирелә. Аның 29 проценты – республика, 19 проценты шәһәр бюджетыннан булса, 52 процент чамасы – милекчеләр керткән акча.

КҮРШЕЛӘРДӘ

Апрель аенда Казанда башкорт режиссеры Айнур Аскаровның «Из Уфы с любовью!» лирик комедиясенең премьерасы булачак, дип яза «Татар-информ». «Из Уфы с любовью!» – бөтенроссия прокатына чыга торган беренче башкорт фильмы. Ул Уфа, Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан һәм башка зур шәһәрләрдә күрсәтеләчәк. Фильм – мәхәббәт, бәхет һәм дуслык турында лирик комедия. Фильм Башкортстан Республикасы Башлыгы грантына төшерелгән. Грант суммасы – 4,5 млн сум. Айнур Аскаров Татарстан тамашачысына Казан халыкара мөселман кинофестивалендә катнашкан фильмнары аша яхшы таныш. Аның «Енмеш» кыска метражлы фильмы Казан кинофестивалендә үз номинациясе буенча җиңү яулаган иде.

* * *

Чувашиядә Республика медицина профилактикасы үзәге белгечләре офис хезмәткәрләре өчен физик күнегүләр комплексын эшләгән. Алар сүзләренчә, яңадан-яңа һөнәрләр барлыкка килә, аларның күбесе бер урында хәрәкәтсез утыру белән бәйле. Белгечләр шул уңайдан төрле физик күнегүләрне үз эченә алган видеоклип төшергән.

* * *

Мари Эл Республикасының 100 еллыгы уңаеннан республиканың Мәдәният, матбугат һәм милләтләр эшләре министрлыгы рәсми логотип эшләргә булган. Әлеге уңайдан министрлык конкурс игълан иткән. Логотип Мари Элның табигатен дә, этнокультурасын да, төбәкнең икътисади үзенчәлеген дә чагылдырырга тиеш.

АТНА ФОТОСЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

АКТУАЛЬ ТЕМА

Узган атнада Үзәк банк Татарстандагы берничә банкның («Татфондбанк», «Интехбанк», «Анкор Банк») лицензияләрен алуы турында хәбәр итте. Юкса, көймәсе комга терәлгән «Татфондбанк»ны терелтә алучы санаторлар барлыгы турында да әйтелгән иде. Вакыйга нинди үсеш алырга мөмкин? Бу хакта Казан федераль университеты профессоры, икътисад фәннәре докторы Игорь КОХ белән сөйләштек.

«Акчагызны берничә банкта саклагыз»

– Игорь Анатольевич, банкның лицензиясен алу нәрсәгә китерә? Кертемчеләр моңардан нинди файда һәм нинди зыян күрә?

– Лицензияне алу банкларны ликвидацияләүгә, икенче төрле әйткәндә, банкротлыкка китерә. Конкурс идарәчесе банкның мөлкәтен сату эшләре белән шөгыльләнәчәк, шуннан кергән акча клиентларга кертемнәрен түләүгә тотылачак. 1 миллион 400 мең сумга кадәр булган кертемнәрне физик затлар Кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгы аша ала алды, бу суммадан артып киткән акча банкны ликвидацияләгәннән соң бирелә. Беренче булып физик затларга, аннан соң гына башка кредиторларга акчалары кайтарыла. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр дә кертемнәрен алуга ирешә ала, әмма шунысы бар: ликвидацияләү бер елга һәм аннан да озаккарак вакытка сузылырга мөмкин.

– «Татфондбанк» шәхсән сездә ышаныч тудыра идеме?

– Мин аның эчке торышы белән таныш түгел идем, эшчәнлеген ныклап анализлаганым да булмады. Тышкы яктан караганда, ул башка банклардан аерылып тормады. Соңгы елларда «Татфондбанк»ның кыенлыклары булды, әмма ул аларны һәрчак бетерә килде.

– Соңгы арада республиканың төп банкы – «Ак барс» банка карата мәгълүмати һөҗүм башланды: кертемчеләргә «банк озакламый бөлгенлеккә чыгачак, акчаларыгызны алырга ашыгыгыз» дигән эчтәлектәге sms-хәбәрләр килә. Ничек уйлыйсыз, бу кем эше булырга мөмкин? Мондый күренеш банк системасында никадәр еш күзәтелә?

– Дөрестән дә, мондый һөҗүмнәр еш булгалый. Кагыйдә буларак, моның ике төрле сәбәбе бар. Беренчесе имеш-мимешкә кайтып кала, кемдер нәрсәдер ишетеп, икенче берәүгә җиткерә дә, нәтиҗәдә бу гайбәт тарала башлый. Икенче сәбәп: көндәш банклар бу эшне максатчан рәвештә башкара. Куркуга калган клиентлар акчаларын шушы банктан алып, башкаларына күчерергә ашыга.

– Ничек уйлыйсыз, төбәк күләмендәге банкларның киләге бармы? Әллә халыкка федераль банклар гына да хезмәт күрсәтә алыр идеме?

– Федераль банклар техник яктан илдәге бөтен халыкка хезмәт күрсәтә алыр иде. Шул ук вакытта икенче бер сорау туа: федераль яки башка төбәк банклары Татарстан икътисады үсешенә ниндирәк өлеш кертә алыр икән? Алар, бездәге акчаны туплап, аны башка төбәкләрдәге проектларга тотарга мөмкин. Төбәк банклары, беренче чиратта, үз җирлекләрендәге икътисадны финанс ресурслары белән тәэмин итү максатын күздә тота. Татарстан кебек эре сәнәгать төбәкләренең үз финанс институтлары: банклары, иминиятләштерү, инвестицияләү компанияләре булуы бик мөһим.

– Халыкны хәзер, мөгаен, акчаны кайда саклау мәсьәләсе борчый торгандыр. Нинди киңәш бирә алыр идегез?

– Теләсә кайсы банкта 1 миллион 400 мең сумга кадәрге кертемнәр иминиятләштерелгән. Шуңа күрә мондый сумманы кайсы банкта сакласаң да була. Декабрьдә «Татфондбанк» эшчәнлеге туктатылгач, кертемчеләр акчаларын инде ике атнадан ала башлады. Әгәр акчаларыгыз 1 миллион 400 меңнән артып китсә, аны шушы суммадан арттырмыйча, өлешләп, берничә банкка салырга кирәк.

Линар ЗАКИРОВ.

P.S. Соңгы арада банкларның күбесе үз капиталын арттыру максатында субординацияләнгән займ алымын кулана. «Ак Барс» банкы да әлеге хөкүмәт программасында катнаша. Программа таләпләре буенча, «Ак Барс» банк Иминиятләштерелгән кертемнәр агентлыгы каршында устав капиталын арттыру буенча үз бурычын үтәгән. Бу – банкның тотрыклы булуына тагын бер дәлил.

«Татфондбанк»: нәрсә

RealnoeVremya.ru

Белгечләр «Татарстан банклары белән бәйле вазгыять республиканың икътисадына зур йогынты ясамаячак» дип фаразлый. Россия Үзәк банкы рәисе Эльвира Нәбиуллина «Россия 24» телеканалына биргән әңгәмәсендә «банк секторы күзлегеннән Татарстанның банк системасында вазгыять тотрыклы» дип ышандырды. Россия Президенты Владимир Путинның матбугат сәркатибе Дмитрий Песков та Үзәк банк лицензияне алу турында карар кабул иткәндә, төбәкнең барлык финанс тотрыклылыгы аспектларын исәпкә алганын ассызыклады.

Ничек кенә булмасын, моны кризисның тәэсире дип танырга кирәк. Кредит оешмалары банк операцияләрен башкару хокукыннан мәхрүм булуына карамастан, кредиторларның таләпләрен игътибарсыз калдырмаячаклар. Россия Үзәк банкы Татарстан җитәкчелеге белән берлектә «Татфондбанк»ка бәйле хәлне чишүдә актив эш алып бара – алар кертемчеләрне, шул исәптән юридик затларны да яклау юлларын эзли. Банклар белән бәйле хәлләрдән соң Президент Рөстәм Миңнеханов ашыгыч киңәшмә уздырды. Ул «банк активлары читкә чыгарылмаска тиеш» дигән бурыч куйды. Әлеге чара банкның зыян күргән клиентларына түләүләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Татарстан премьер-министры Илдар Халиков «Татфондбанк» һәм «Интехбанк» кертемчеләре белән очрашу вакытында банк белән бәйле вазгыятькә үз аңлатмасын бирде: «Бу хәлдән чыгуның ике юлы бар: Үзәк банк карарын кире алдыру яки банкларның банкротлык процедурасын башлау. «Татфондбанк»ның бүлендеге – «ТФБ Финанс» клиентларының хокукларын банк кертемчеләренеке белән тигезләүдә юридик мөмкинлекләр эзләү дә мөһим. Бу алданган «ТФБ Финанс» кертемчеләре Кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгы аша акчаларын кайтара алсыннар өчен кирәк», – диде.

Татарстанның Икътисад министрлыгы матбугат үзәге җитәкчесе Инсар Сәгыйтов аңлатуынча, хәзер «Банкротлык турында»гы Федераль закон нигезендә конкурслы идарәче яки «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында»гы 23.1 Федераль закон буенча ликвидатор билгеләнгәнче, «Татфондбанк», «Интехбанк», «Анкор Банк» белән вакытлыча администрация идарә итә.

– Вакытлыча администрациянең төп бурычларының берсе – кредит оешмасының милкен бәяләү, банкротлык билгеләрен ачыклау һәм Үзәк банкка кредит оешмасын банкрот дип тануны сорап үтенеч язуы әзерләү. Вакытлыча администрация клиентларның банкларга карата таләпләрен ачыклау өчен аларны, кредиторларның таләпләре реестрына исәпкә куя. Әлеге реестрга элөгү өчен, кредиторлар үзләре турында мәгълүмат (исем, фамилия, туган ел, яшәү урыны һ.б.) бирергә тиеш. Арбитраж суды тарафыннан әлеге банкрот дип игълан ителсә, бер елга конкурслы җитештерү (конкурсное производство) ачыла. Конкурслы идарәче сайлап алына. Аның төп бурычы – кредиторларның таләпләре реестрын, конкурс массасын формалаштыру. Конкурслы идарәче кредиторларның таләпләрен канәгатьләндерү даталарын раслый. Кредиторларның таләпләре үтәлеше суд ярдәмендә хәл ителә, – дип шәрехләде «ШК»га Инсар Сәгыйтов.

Икътисади терминнарның гади халык теленә күчерсәк, конкурс массасы ул – банкның милке. Лицензиясе алынган һәр оешманың билгеле бер кыймммәткә ия күчемсез милке, финанс активлары була. Аларны конкурслы идарәче бәяли. Шул суммадан чыгып, кредиторларның таләпләрен канәгатьләндерү чираты билгеләнә. Инсар Сәгыйтов әйтүенчә, килешү нигезендә клиентлары гомеренә, сәламәтлегенә зыян китергән очракта банк җавап тота, шуңа да физик затларның мәнфәгатьләрен беренче чиратта канәгатьләндерәчәкләр. Икенче чиратта хезмәт килешүе нигезендә банкта эшчеләренең хезмәт хаклары, пособиеләре түләнә. Калган зыян күрүчеләрнең таләпләре өченче чиратта канәгатьләндереләчәк.

Банк белән бәйле хәлләрдә таяның юан башы

Кертемнәрне кайтару турында тулырак мәгълүматны Кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгының «кайнар элемтә» номеры (**8-800-200-08-05**) аша, шулай ук агентлыкның сайтында «Иминият кертемнәре/Иминият очраклары» (www.asv.org.ru) бүлекчәсендә дә укырга була.

көтәргә?

Татарстан Президенты
Рөстәм МИҢНЕХАНОВ:

– Без үз өстебездән җаваплылыкны төшермибез. Төп хатабыз – банкның финанс тотрыклыгына ярдәм итүебездә булгандыр. 2014 елда сум очсызлангач, бөтен банкларда да хәлләр катлаулыланды, шул чакта «Татфондбанк»ның җитәкчесе Роберт Мусин ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән иде. Банкның финанс тотрыклылыгын тәэмин итү өчен кайбер адымнар ясалды. Кызганыч, хәл уңайланмады, 2016 елда банкка тышкы ярдәм кирәклеге билгеле булды. Илдар Халиковка Үзәк банк җитәкчелеге белән очрашып, санатор эзләү бурычы да куелган иде. Банк белән эчке идарәче җитәкли башлагач, хәлнең без уйлаганнан да катлаулы икәне аңлашылды. Банкны торгызуда «ТАИФ» компанияләр төркеме ярдәм итәргә әзер иде. Шундый ультиматум да куелды: «ТАИФ» белән «Татэнерго», башка компанияләрдән акчалар алабыз да кертемчеләргә өләшәбез, имеш. Әмма моны эшләргә берәүнең дә хакы юк. «Татнефть» тә башка компанияләр кебек үк акчаларын югалтучылар исемлегендә. Халыкка моны аңлатуы да катлаулы. Кешеләрнең дәгъваларын да аңлыйм. Монда проблема бик тирәндә. Үзәк банкның финанс моделе буенча проблеманы хәл итү өчен 40 миллиард сумнан күбрәк акча таләп ителә. Үзәк банкка карата бер сүзем дә юк. Ул безгә иминиятләштерелгән кертемнәрне кайтаруда ярдәм итте. 50 миллиард сумга кадәр акча бүлеп бирде. Үзебез дә кушылдык. Әмма башка проблема калкып чыкты – «ТФБ Финанс». 1,7-1,8 мең кешенең кертемнәрен банкның башка тармакларына күчергәннәр белмәдек. Алар дәүләт иминиятләштерүеннән мәхрүм калды. Хәзер барлык хокук саклау системасы менеджерлар гаебен билгеләү өстендә эшли. Кулга алынучылар бар, тагын булуы ихтимал. Бүген кертемчеләрнең эше белән прокуратура шөгыльләнә. Җиңел эш түгел. Бу кешеләр бүген билгесезлектә. Бары суд кына гадел карар кабул итә алыр. Кертемнәре 1,4 миллион сумнан арткан клиентлар белән дә проблемалар бар. Хәзер иң мөһиме – «Татфондбанк»та акчасын башка кертем формасына күчергән гражданнарның хокукларын яклау. Шулай ук банкта булган активларны реализацияләү хисабына физик затларга акчаларын кайтару.

(Хатын-кыз журналистлар белән очрашуда чыгышыннан.)

эшмәкәрләргә төште кебек. Күпләргә барысын да яңадан башларга туры киләчәк. Татарстанның бизнес-омбудсмены Тимур Ногманов банк лицензиясе алыну сәбәпле бәладә калган эшмәкәрләргә ярдәм бирү йөзеннән нишләргә кирәклеген үзенең Инстаграм битендә дә аңлатып язган иде. Закон нигезендә, бу очракта кредиторлар компенсация алырга хокуклы. Зыян күргән кертемчеләргә кредиторлар реестрына эләгү өчен Кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгына гариза белән мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Гаепләләргә килгәндә, «Аеруча зур күләмдә акча үзләштерү» маддәсе буенча инде биш кеше кулга алынды. Алар барысы да «ТФБ Финанс» («Татфондбанк»ның бүлендеге) инвестиция компаниясеннән барлыгы 90 миллион сум акча урлауда гаепләнәләр. «Татфондбанк»ның элекке җитәкчесе 52 яшьлек Роберт Мусин исә 16 апрельгә кадәр сак астында булачак.

8 Март бәйрәме алдыннан «Мега» сәүдә үзәгендә гүзәл затларга бүләк ясадылар – Республика клиника онкология диспансерының табиблары аларга бушлай тикшерену үткәрде.

Авырмасагыз да, табибка күренегез

Күкрәк бизе рагы – Татарстанда яман шеш авырулары арасында өченче урында тора. Хатын-кыз авырулары арасында – беренчедә. Узган ел республикада яшәүче 1604 хатын-кызда әлеге авыру ачыкланса, биш ел дәвамында учетта торучыларның саны 10 меңгә җитә.

– Безнең бурыч – күкрәк яман шешен беренче һәм икенче стадиядә ачыклау. Бу максатка төрле чаралар ярдәмендә ирешәбез дә. «Яңа барлыкка килгән шешләргә каршы белем бирү» проекты да, һичшиксез, уңай нәтиҗәләрен бирә. Ниндидер төерләр барлыгын сизү белән үк, кичекмәстән табибка барырга кирәк. Бетәр әле, дип йөрергә ярамый. 67 проценттан артык очракта күкрәк рагы беренче һәм икенче стадиядә ачыклана. Шул очракта аны җиңәргә дә мөмкин. Авыруга алып килә торган төерләрне, төрле проблемаларны һәрвакыт күзәтеп торырга кирәк. Аннан соң, якын туганнар арасында да күкрәк рагы белән авыручылар булса, сәламәтлеккә тагын да игътибар бирү таләп ителә. 27 процент очракта авырулар нәкъ менә медицина тикшеренүе үткән вакытта билгеле була. Безнең Европа дәрәҗәсендәге операцияләр ясарга сәләтле пластик хирургларыбыз да бар, – диде Татарстанның сәламәтлек саклау министры Адел Вафин.

Республика клиника онкология диспансерының баш табибы Илдар Хәйруллин да министрның фикерен куәтләде.

– Иң мөһиме – бер җиребез дә авыртмаганда табибка күренү, ягъни профилактика культурасына зур игътибар бирү. Статистика күрсәткечләре буенча, яман шеш барлыкка килү куркынычы 50 яшьтән өлкәнрәкләрдә күзәтелә. Шуңа күрә 45 яшьтән узган хатын-кызларга даими рәвештә тикшерену узарга киңәш итәбез. Яшьрәкләр өч елга бер тапкыр үтсәләр дә була. 40 яшькә кадәр УЗИдан карасак, аннан өлкәннәргә маммография тикшеренүе уздырабыз, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

Кызыксындырган сорауларыгызны редакциягә **(843) 562-50-03, 8(917) 851-69-62** телефоннары аша җиткерә аласыз.

Октябрьдән башларга?

Билгеле булганча, 3 декабрьдән инвалидларга ярдәм итү ункөнлеге үткәрелә. Әмма мин, бу уңайдан уздырыла торган чараларны октябрьдән үк башларга кирәк, дигән фикердә. Чөнки декабрь, гадәттә, карлы, салкын ай, юлларда бозлавык. Инвалидлар юлга чыгып йөри алмый. Бу хактагы тәкъдим белән Россия Президенты Владимир Путинга да хат юллаган идем. Бу эшне Татарстан Министрлар кабинеты хәл итә дигән җавап килде. Чарасызлыктан, әйтәсе сүземне җитәкчелеккә ишеттерер өчен, «Шәһри Казан»га язарга булдым. Октябрьнең җиде көнендә спорт ярышлары, музей-кинотеатрларга йөрү кебек чараларны уздырырга кирәк. Ә декабрьдә чәчтараш, медицина хезмәте күрсәтү, изгелек марафоны кебек акцияләр оештырылсын иде.

Миннефлюс ФӘРХЕТДИНОВ,
Актаныш районы,
Югары Яхшый авылы.

Миннефлюс әфәнде, сезнең үтенечне Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына җиткердек.

– 1992 елда Берләшкән Милләтләр Оешмасы Генераль ассамблеясы 3 декабрьне Халыкара инвалидлар көне дип игълан итә. Инвалидларның хәлен яхшырту һәм алар өчен тигез мөмкинлекләр булдыру, хәбәрдарлыкны арттыру максатында, ел саен бу көнне бөтен дөньяда Инвалидлар көне билгеләп үтелә. Моның белән бәйле рәвештә Татарстанда да барлык муниципаль районнарда декабрь башында инвалидлар декадасы уза. Декада кысаларында түгәрәк өстәл, ярышлар, хәйрия акцияләре һәм башка чаралар оештырыла. Инвалидларга бушлай музейларга керү, социаль, юридик ярдәм алу мөмкинлеге бирелә. Физик яктан мөмкинлекләре чикле яшь кешеләрне эшкә урнаштыруда вакансия ярминкәләре оештырыла. Шуны да әйтергә кирәк, инвалидларның хәлен яхшырту буенча эш республикада ел дәвамында алып барыла. Актаныш социаль яклау бүлеге аңлатуынча, «Шәһри Казан» газетасына мөрәҗәгать иткән Миннефлюс Фәрхетдинов яшәгән җирлектә инвалид кешеләргә ярдәм күрсәтү өлкәсендә барлык эшләр дә башкарыла. Бу хакта норматив-хокукый актлар кабул ителгән. Әйтик, Актаныш районы башкарма комитеты карары белән, инвалидларга уңайлы мохит тудыру өчен, 2016-2020 елга чаралар планы булдырылган. Физик яктан мөмкинлекләре чикле кешеләр уздырылган барлык чараларда актив катнашалар. Шуны да әйтергә кирәк, барлык чаралар, «Татарстанның инвалидлар җәмгыяте» оешмасы тәкъдиме белән, инвалидларның теләген, мәнфәгатьләрен истә тотып аларга җайлы вакытта оештырыла. Бу чаралар турында матбугатта – «Актаныш таңнары» район газетасында, җирле радио, Актаныш районының рәсми сайтында хәбәр итеп бараларр, – диделәр министрлык белгечләре.

Кыскасы, сез үзегез дә теләк-тәкъдимнәрегезне район социаль яклау бүлегенә җиткерә аласыз. Инвалидлар үзләренә карата игътибарны декада уңаеннан гына түгел, һәрчак тойсыннар иде.

Инвалидларга ярдәм

Апабыз – I группа инвалид. Моңа кадәр алар әни белән икесе генә яшәде. Ул вафат булгач, туганыбызны үзебезнең янга алдык. Шуңа күрә күп кенә нәрсәләрне белеп бетермибез. Социаль ярдәм алыр өчен кая мөрәҗәгать итәргә кирәк? Гомумән, республикада инвалидларга ярдәм күрсәтә торган нинди оешмалар бар?

Гөлнур ИСЛАМОВА,
Казан.

Татарстанда алты тернәкләндерү үзәге бар. Казанда – «Восхождение» инвалидларны тернәкләндерү үзәге, республикада мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен 13 тернәкләндерү үзәге (шуларның өчесе Казанда) эшли. Социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә стационар формада елына ике тапкыр дәвалану каралган, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә – елына бер тапкыр. Буш урыннар булган очракта, биредә үк инвалидларга стационар формада социаль хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеге дә тудырыла. Социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә ярымстационар формада – елына ике тапкыр, мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен булган тернәкләндерү үзәкләрендә шулай ук елына ике тапкыр социаль хезмәт күрсәтелә.

Истәлек тактасындагы хатаны ничек төзәттерергә?

Арча районының Югары Оры авылында сугышта һәлак булганнар истәлегенә һәйкәл куелган. Әмма анда безнең әтинең фамилиясен хата белән язганнар. Фәхретдинов дигәннәр. Дөреслектә ул Фатыйх Шәрәфи улы Шәрәфиев. Кайткан саен шуңа борчылып, елап киләм. Шушы хатаны төзәтер өчен кая, кемгә мөрәҗәгать итәргә икән?

Рәис ШӘРӘФИЕВ,
Казан.

Бу мәсьәләне хәл итәр өчен Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының иҗтимагый оешмалары белән эшләүче бүлегенә (843) 557-21-21 телефоны аша шалтыратып чыгарга кирәк. Шулай ук мондый проблемаларны (843) 557-21-19 номерына да хәбәр итәргә мөмкин. Болардан кала, халык белән эш буенча секторының «кайнар линия»сенә хәбәр итәргә була. Аларның телефон номерлары – (843) 557-21-12 һәм 557-19-36. Кайвакыт, бу «кайнар линия» эшләми дип, шикаятьләр килә, чөнки шалтыратуларны автоҗавап кабул итә. Әмма андагы мөрәҗәгатьләр тыңлана һәм тиешле чаралар күрелә.

Автор фотолары

ҮЗЕМ СЫНАДЫМ

Боз өстендә балыкчы

Абыемның балыкчы булып китүе язның ямен алды. Балык тотам дип, язгы боз өстенә кер инде. Җитмәсә тагын көн саен әле аннан, әле моннан шомлы хәбәрләр килеп кенә тора: берсе төшеп киткән, икенчесе боз белән аккан. Аларның мәшәкатен әйт син, хәтта вертолетлар белән эзлиләр үзләрен. Исән-сау булсалар, мең шөкер инде анысы. Аллам сакласын, харап булганнары да җитәрлек.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

Инде тагын балыкчылар, алардан да бигрәк гаиләләре өчен куркыныч көннәр җитә, бик тиздән боз кузгалачак. Һәм, әлбәттә инде, елдагыча: «Балык тотарга бармагыз», – дип кисәтеп торуга карамастан, аны бер генә балыкчы да колагына элмәячәк. Аларның фәлсәфәсен аңлар өчен, үзем дә балык тотарга барып карарга булдым. Сүз дә юк инде, күрә торып язгы боз өстенә керерлек балыкчы түгел мин, шуңа күрә кышның язга авышкан чорын сайладым. Чатнама суыкта балык эзләп йөрүе дә инде аның...

БАЛЫК ТАВЫШНЫ ЯРАТМЫЙ, ШУЛАЙ ДА...

Гаиләдән кемнең дә булса балыкка баруы күп вакыт тавышның башы була. Безнең гаилә генә искәрмә була алмады.

– Махсус кием кирәк анда, туңып кайтып, авырыйм дип йөрмә монда, – диде ирем.

Сүз дә юк, һәркайсыбызда да кием базар ачарлык. Шулай да, балык тотарга барганда, махсус кием кирәк. Бүген аның ниндиләре генә юк. Иң яхшылары суны тиз генә сеңдерми икән. Хәтта суга төшеп китсәң дә, тиз генә батмыйсың, имеш. Шулай да иң мөһим шарт — җиңел генә хәрәкәтләнеп булсын һәм җил үткәрмәсен. Кием эзләп базарга барасы булмады, абыем үзендәге запас киемнәрен бирде. Аяк киеме – бер мең сум, бик җайлы һәм аякны бер дә тундырмый. Чалбары белән курткасы – дүрт мең сумлык. Бияләй һәм башлыкларның булганын кидем. Димәк, якынча биш мең сумга киенергә була.

Кием хәстәрле башлаган минуттан шуны аңладым: балык тоту бик очсыз шөгыль түгел. Сезонына, нинди балык тотарга теләвеңә карап, кармакларын, алдавычларын, җимнәрен әзерләргә кирәк. Әле күптән түгел генә Казанда балыкчылык һәм аучылык буенча күргәзмәдә булырга туры килгән иде, бу тармакның ничаклы алга киткәнлегенә хәйран калдым. Нәрсә генә сатмыйлар. Болар бар да – акча җимеше. Юкка гына балыкчылар бар нәрсәне «кармак эквивалентына» күчереп сөйләшми. Әле дә ярый хатын-кызлар күп нәрсәнең бәясен белми... Менә шуннан соң әйтелә инде, балык үзе тавышны яратмаса да, тавыш куптарырга ярата, дип.

ЗУР СПОРТ

Тар сукмак аша елгага таба атлыйбыз. Сукмактан аз гына читкә авышсаң, бил тиңентен төшәсең дә китәсең. Кыз вакытта чишмәгә суга йөргәннәр искә төште. Тулы ике чиләк белән дә туп-туры йөри торган идек. Менә кайда булган икән ул подиумда йөрү буенча мастер-класслар! Бар да онытылган, балыкчылар артыннан көчкә җитешеп барам. Абыем Харис Һадиев сөйли дә сөйли:

– Балыкка бер дә йөрмәгән кешеләр, машинага утырып баралар да, аннан соң боз өстенә кереп утыралар дип, уйлыйлардыр инде. Күп вакыт, ким дигәндә, җиде чакрым җәяү керәбез. Балык тотуны юкка гына спорт димиләр ләбаса. Арка лычма су була. Аннан соң инде борау белән тишек тишәсең, монда да бик күп көч кирәк. Кайчакта 50шәр тишек тишәргә туры килә.

Миңа берсе дә җитте. Нәрсә, нәрсә, балык тотуның зур спорт икәнлегенә бик тиз инандым. Күп хәрәкәтләнү – бер булса, икенчесе – балык тоту сабырлык, сизгерлек сорый. Оят булса да әйтим, мин балык тоту технологиясен бөтенләй белмәгәнмен икән. Моңарчы кармакка җим кигезәләр дә, җимне ашыйм дип балык шуны каба да кармакка эләгә дип уйлый идем. Юк икән шул. Син үзең нәкъ менә минутын гына түгел, секундын тоеп кармакны тартып (анысы да нәкъ кирәгенчә), аны балык авызына каптырырга тиеш. Кыш көне балык тоту бик тә мавыктыргыч санала икән.

– Җәй көне матур, рәхәт, сандугачлар сайрый, – дип кызыктырам бәке авызына карап утыручыларны.

– Сандугачына түзеп була, черкие бик яман, – диделәр алар миңа каршы.

– Кышын балык тоту фантазиягә чиксезлек бирә. Күз алдыңа китер, сулыкның үзең теләгән урынына барып утыра аласың. Җәй көне хәтта көймә белән дә бар урынга да тукталып булмый. Тагын шунысын да әйтергә кирәк, боз өстеннән йөргәндә беләсең: аяк астында балык бар. Һичшиксез бар ул анда, һәм син аны тотачаксың, – ди абыем.

ФӘЛСӘФӘ

Сәфәремнең төп максаты балыкчы фәлсәфәсен аңлау иде бит. Салкында да, яңгырда да нәрсә йөртә аларны? Иң элек акыллы китаплардан укыганым белән уртаклашыйм: аучылык иргетләрнең геннарына ук салынган була икән. Шуңа күрә аларның балыкчылык яки аучылык белән кызыксынып китүләре бер дә юк урыннан түгел, кечкенә генә бер сәбәп кирәк һәм сезнең ирегез – балыкчы. Ни өчен бу балыкчылар күрә торып үзләрен куркыныч астына куялар? Бактың исә син бер ел тота алмаган балыгыңны беренче яки соңгы бозда тота аласың икән. Ягъни боз катар-катмаста балыклар бик актив була, бу көнгә туры килсәң, капчык белән балык синеке. Елга боздан ачылам-ачылам дигәндә дә шул ук хәл. Сүз дә юк, азарт дигән нәрсә дә бар, ничек инде аннан башка. Ярый белән ярамыйны җиңел генә чикли белсә, адәм баласы буламыни инде ул.

БЕЛЕП ТОР!

БОЗНЫ СЫНЫЙБЫЗ

Бозның калынлыгын күз белән дә якынча билгеләргә була. Зәңгәрсу яшел төстәге боз нык санала. Аксыл булып торганы якынча ике тапкырга юкарак. Ә инде көрән, тонык ак яки саргылт төсләр булса, боз өстен читтән генә күзәтү яхшырак. Чын саннар теленә күчсәк, бозның ныклыгы аның өстендәге кешеләр саны белән билгеләнә, аерым кеше генә барганда аның калынлыгы 10-12 см булырга тиеш. Берничә кеше булса – 15-20 см. Иң куркынычы – кар астындагы боз, кар астында катмый торган агым булырга мөмкин.

БИК МӨҺИМ ГАП-ГАДИ КАГЫЙДӘЛӘР

- Бозның ныклыгын аяк белән тибеп тикшермиләр. Боз өстеннән елга аша бары тапталган сукмактан гына барыгыз. Берничә кеше барасы икән, ике кеше арасы, ким дигәндә, 10 метр булсын.
- Рюкзагыгыз булса, аны аркага кимичә, кулыгызда тотып барыгыз – боз ярыла башласа, читкә ыргытырга җайлырак булыр.
- Боздан суга төшеп китсәң, нишләргә? Бик куркыныч булса да, паникага бирелмәскә, шул ук вакытта исегездә тотыгыз: кеше бозлы суда, күп дигәндә, 10-15 минут тора ала. Димәк, тиз арада акыл белән котылу чарасын табарга кирәк. Кием эчендә барлыкка килгән һава мендәрчеге кешене су төбенә китүдән күпмедер вакыт саклый. Киемгә су сеңгәч, бу ярдәм юкка чыга һәм сезне аска тарта башлый. Кулны ике якка җәяргә һәм тиз арада мөмкин булган авырлыклардан котылырга кирәк. Бик еракта булса да, кеше барлыгын белсәгез, ярдәмгә чакырыгыз, боз өстеннән тавыш ерак араларга барып җитә. Башыгызны суда чылатмаска тырышыгыз. Ничек кенә булса да, гәүдәнең күбрәк өлешен судан чыгарырга тырышыгыз. Кискен хәрәкәтләр ясамагыз, боз тагын ватылыр. Тәрәзә төбенә сикереп утыргандагы кебек, судан этелеп чыгарга тырышып карагыз. Каты боз өслегенә чыгасыз икән, аягүрә басмагыз, шуышып яки мүкәйләп барыгыз. Иң яхшысы – үзегез килгән якка кире бару, сез инде ул урында бозның ныклыгын беләсез. Шуны истә тотыгыз, боз ярга таба ныграк була.
- Кемне дә булса коткарырга туры килсә, аның янына бик якын килмичә таяк, бау, шарф сузыгыз. Батучыны коткарырга барганда, аяк-кулларны ике якка җәеп шуышырга кирәк. Ул аны эләктерә алса, сез аны тартып алачаксыз. Үз-үзеңне коткарасыңмы, башка кешегә ярдәм итәсеңме, башта «Ашыгыч ярдәм» хезмәтенә шалтыратыгыз. Салкын су кеше сәламәтлегенә бик куркыныч. Тиз арада юеш киемне салдырырга, алмаш кием булмаса, сыгып кидертергә кирәк. Спиртлы эчемлек эчертмәгез, нәтиҗәсе бик начар булырга мөмкин. Аракы бар икән, иң яхшысы – шуның белән кешенең тәнен ышку.
- Иң мөһиме, балык тотам дип, башны бәкегә тыгасы түгел, җәмәгать.

8 Март тирәләрендә, табигый ки, хатын-кызлар турында уйлар күбәеп китә. Кемнәр генә очрамаган икән тормыш юлында?! Бик күп ярдәм, игелек, шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек биргәннәр икән миңа хатын-кызлар, ә тагын күпме тәҗрибә! Шул йөзәрләгән кызлар, ханымнар, әбиләрнең һәрберсе турында аерым китап язарлык, чөнки ир-ат күңелен тулы бер планета белән чагыштырып булса, хатын-кызныкы – галактика!
Тик шулай да хәтердә мәңге җуелмас эз калдырган очрашулар була. Шундыйларның берсе 2009 елда Актанышта узды. 90 яшен тиздән тутырасы Гөлҗиһан Газетдинованы шаккату катыш соклану хисләре белән тыңлап утырдым мин. Шулкадәр авыр сынаулар үтеп тә, ничек бу кеше күңел көрлеген, юмор хисен, бу тормышка булган олугъ мәхәббәтен югалтмаган? (Ни кызганыч, бу якты дөньядан китте инде ул...)
Аннары «Сигезле бию» спектаклендә Нурлыбәян әби образы туды. Шунысы бар: сәхнәдәге образ – күмәк иҗат җимеше. Ул әйткән сүзләрне драматург яза, актриса үтемле итеп сөйли, режиссер үз акцентларын куя, рәссам бу образны киендерә, композитор ул тамашачының күңел түренә кереп утырырлык музыка яза һ.б. Ахыр чиктә реаль прототиптан шактый ерак кителә. Ә мин пьеса язарга әзерләнгәндә, рәссамнарча әйткәндә, гади карандаш белән тиз генә, штрихлап кына бу әбекәйнең портретын ясап куйган идем. Күңелдәге хисләр суынырга өлгергәнче дип. Бу хикәят образны спектакльдәгегә караганда тулырак ача, минемчә. Аннары ул реаль тормыштагы прототипка күпкә якынрак, шуның белән кадерлерәк тә. Менә сез дә укып карагыз әле...

«МИНЕМ ЧИРАТ ИДЕ...»

КӨЧЛЕ РУХЛЫЛАР

Равил САБЫР

– Тыңла син, улым, әбиеңне, тыңла! Мин сөйләгәннәрне сиңа беркем дә сөйләмәс. Аларның әле авыз кырыйларындагы сөтләре дә кипмәгән, ә әбиең – дөнья күргән корткa ул! Дөрес, мин дә карт түгел әле! Егерме яшь тулганга җитмеш ел да узмады! И-и-их, егерме яшькәйләрем! Үлем белән уйнап узды шул яшьлегем. Алай да ил белән күтәргән кайгы авыр түгел икән ул, улым. Менә берүзеңнең газиз башкайларыңа төшсә, анысы авыр... Берүзең күтәрәсең бит.

Тәртибе белән сөйли китсәң, ул менә болайрак була инде, улым. 19 яшемдә, 1939 елда, авылдан чыгып киттем мин. Ике ел кумбайнюр пумушнигы булып йөргән идем, калхуздан, кумбайнюрга укып кайт, дип бер еллык паспорт биргәннәр иде. Миңа шул гына кирәк! Уку-мазарларга барып тормадым, бик әйбәтләп кенә җыендым да Ленинградка китеп бардым.

Анда абзыкаем тора иде гаиләсе белән, шуның янына барасым килде. Өзелепләр сагынган идем инде менә абзыкаемны! Бик якын идек без аның белән. Әниебез мин ике яшьлек чакта бәбәйдән үлеп киткән, абзыкаем миңа әниемне алыштырган кеше иде. Бәләкәй чагымда мунчаларда үзе белән бергә юындырып, чәчләремне матур итеп үрә торган иде. Нурлыбәян дип эндәшкәнен бер дә хәтерләмим, гөлкәем дип кенә тора иде, мәрхүмкәем! Ул Ленинградка миннән өч-дүрт ел алдан барып урнашты, кулак малайларына ияреп киткән иде...

Туктале, ничек булды соң әле ул?.. Ай, Алла, бик исемдә иде әле...

Ә-ә-ә! Абзыкаемны сагыну да булгандыр инде... Тагын бер сәбәбе бар иде әле аның, сиңа сөйләсәң ярый инде. Эчемне бушатыйм әле бер, сөйләр кеше юк бит бүтән...

Күршедә бер бик шәп егет тора иде. Шул өйләнеп куйды бит, нәгаләт! Үзе болай гел сөйләшеп тә йөргән кебек иде, шаярткан гынадыр инде, күңелендә мин булмаганмындыр. Әйе шул, килен алды да кайтты бу! Ничек шуңа түзеп тормак кирәк?! Киттем дә бардым мин Ленинградка!

Абзыкаем бик сөенеп каршы алды, җиңгәчәм дә бик әйбәт кеше иде. Ленречстрой дигән җиргә эшкә урнаштырдылар, упшыжитиедан урын алып бирделәр. Әйбәт кенә яшәп ята идек, сугыш башланды. Бөтен кешене оборона эшенә җибәрделәр.

Җигә белгәч, миңа ат бирделәр. Озын-озын бүрәнәләрне Ладогадан суырып алалар да ат арбасына төйиләр, мин шуларны ташыйм ат белән, дотлар төзибез. Син әле дотның ни икәнен дә белмисеңдер! Башта бик олы чокыр казыйлар. Шунда төшереп утырталар орудие. Шуннан өстен бүрәнәләр белән каплыйлар, бүрәнәләргә зурзур ташлар салалар, таш өстенә ком, аннан соң тагын бер кат бүрәнә. Шулай катлы-катлы итеп төзиләр – нәпләвәйт аңа бумбы шартласа да!

Абзыкай хатыны белән ике малаен авылга җибәрергә булды – немес шәһәр читендә бит! Көне буе төялде халык мясокомбинатка сыер ташый торган вагоннарга. И җылашалар, и бакырышалар! Киткәне китәм дип җылый, калганы калам, ди! Җиңгәчәй мине дә үгетләгән иде, авылга бергә кайтыйк, дип. Абзыкаемны җәлләдем, Ленинградта калдым шуңа. Инфаркттан соң иде абзыкаем, урысчасы да бик юк иде, ә мин яза белмәсәм дә, әз-мәз укыштырам, үземә кирәкне аңлатам барыбер.

Сигезенче сентябрьдә немес Ленинградка блокада салып куйды. Өстәвенә – авыртмаган башка тимер тарак – эштән кудылар. Нәчәльник килеп җикеренә башлаган иде, бер кызыбыз тегеңә: «Как жандарм кричишь!» – ди. Жандармнар фашистларда була, дип, бөтен бригадабыз белән куды да чыгарды. Шулай итеп иждивинчиский картычкага калдым, балакаем. Эшләсәң, көненә 250 грамм ипи бирәләр, иждивинчиский белән 125 грамм гына. Әле аның ипие нинди диген? Янган арыштан пешерелгән, авызга кабарлык түгел. Шул ипигә май урынына тоз ягып ашый торган идек, шунсыз ашашлы түгел иде ул. Абзыкаем миңа әйтә: «Аша, гөлкәем!» – ди. Син аша, абзыкаем, мин үлсәм, минем арттан елап калырлык кешем юк, синең балаларың бар, син аша, димен.

Беркөнне абзыкаем кайтты да: «Гөлкәем, миңа рәнҗемәсәң, авыр дип әйтмәсәң, эш таптым мин сиңа», – ди. ГЭЭС-4 дигән җиргә эшкә урнаштырды, вагонеткаларга көрәк белән күмер төйи идек. Гел хатын-кызлар гына. Бери бүлше, кидай дальше! Авыр дип зарланучы юк, барыбыз да эшлибез.

Менә, улым, күрмәгәнгә ул Ленинград, барып күрсәң, ни рад. Гел бизабразиегә әйләнде ул кырык бердә! Башта коеп яңгыр яуды, аннан кисәк кенә туңдырып җибәрде. Менә афәт: бер йөрер хәл юк! Кеше бер егылса, торалмый. «Памагити пажалыста!» – дип ыңгырашып яталар, килеп торгызып карыйм, булдырып булмый. Торгызсаң да аягында торалмый, яңадан егыла. Ач, хәле юк. Бөтен шәһәр тулды мәет белән! Ул эт, песи, күсе дисеңме, бөтенесен пәдрәд ашадылар. Туалетлар эшләми, су юк, ут юк, җылы юк.

Абзыкай һаман мине куырды инде: «Битеңне каплабрак йөр, гөлкәем, тотып ашый күрмәсеннәр!» – ди торган иде. Бик түгәрәк идем мин кыз чакта. Ә үзем бернидән дә курыкмый торган идем. Бомбардирувка башланса, ыснаряд тәрәзәгә очып керер кебек инде менә! Абзыкаем бумбыубижищыга китә торган иде, мин бер дә бармадым. Исән каласымны белдем мин. Төш күрдем берсендә. Кып-кызыл зуп-зур булып кояш чыгып килә икән, дим. Уянгач уйлыйм, исән калам икән әле бу сугыштан соң, дим.

Алай дисәң, курыккан чаклар да булды. Берсендә эштән кайтып киләм, карасам, безнең өйдән ерак та түгел тыртуарда күрше җәбрәй хатыны ята. Чүт кенә калган кайтып җитәргә җанашыма, югыйсә! Юк инде, хәле җитмәгән, ауган. Күт битен кисеп алып киткәннәр иде шуның...

Хуш, кырык икегә дә кердек. Берсендә ике көн ипи китермәделәр. Абзыкаем хәлсезләнде шул чакта. Мин ике көнлек ипи карточкасын алып киттем эшкә, бу өйдә ятып калды. Эштән кайтышлый кибеттән 800 грамм ипи алдым. Ишекне тартып карыйм, бикле. Абзыкайга эндәшеп-эндәшеп карыйм – ачмый. Күршедә Никанур дәдәй белән түте Шура торалар иде, шуларга кердем. Никанур дәдәй балта белән ишекне каерып ачса, абзыкаем ята караватында, җан тәслим кылган.

– Ташлап киттеңмени мине, абзыкаем, – дим, үзем җылый алмыйм, күздән яшь чыкмый.

Өйдә нинди кием бар, бөтенесен дә киеп өстәл артына барып утырдым, мәет саклыйм. Төннең иң озын чагы. Таң беленә башлагач киттем милициягә. Анда халык тулы! Бөтенесе дә шул бер сорау белән килгән минем кебек. Бер справка өчен көне буе утырдым чират көтеп.

Кич кайтып, икенче төнне дә саклап чыктым абзыкаемны. Ашау юк, эчү юк, йокы юк, өй суык. Иртә белән прастиналарга төреп, чанага чана тагып, шунда абзыкаемны салып, моргка тартып алып киттек. Кеше күму юк ул чакта. Алып кереп тапшырдык. Чыктык. Җылыйсы да килә бит инде азрак. Җылый башлаган идем, түте Шура әйтә, җылама, ди. Без бит әле абыеңны кешечә илтеп тапшырдык, әнә кара тегеләргә, ди.

Күтәрелеп карасам, морг капкасыннан өч машина чыгып килә. Кузовыннан да биегрәк итеп мәет төягәннәр. Төрелмәгән-нителмәгәннәр, кайсының кулы тырпаеп тора, кайсының аягы. Урамнан җыелган бит инде болар.

Әзрәк тынычлангач, бер таныш кызларга киттем, аларның өйләре җылы иде. Теге 800 грамм ипине аларга хәер итеп өләштем. Үземнең әле һаман ашыйсы килми.

Икенче көнне эштән, противогаз сумкасына салып, ташкүмер алып кайттым. Тимер мич ягып, бүлмәне җылытырга кирәк бит. Ул көнне якмадым, киләсе көнне тагын бер сумка алып кайттым да бик әйбәтләп кенә ягып җибәрдем. Ярар, бүлмә дә җылынды. Томалап куйдым мичне. Каян белим инде мин, ташкүмер яккач, мичне томаларга ярамаганын?! Ничек исән калган инде мин ул чакта? Шул караваттан идәнгә җыгылып төшү булышкандыр инде...

Туктале, ничек булды соң әле ул?.. Ай, Алла, бик исемдә иде әле...

Ә-ә-ә! Кырык икенең 10 июнендә военкоматка чакырып мобилизовайт иттеләр әбиеңне! Бер ай минерга укыттылар. Менә, улым, мактана дип әйтмә, әйеме, хыт бүген күземне бәйләп, дүрт төрле минаны сүтеп җыя алам! Бик нык өйрәттеләр инде безне, минёр үз гомерендә бер генә ялгыша бит ул.

Ярар, өстә – куфәйкә, билдә – каеш, көненә 500 грамм ипи дә эләгә башлады Нурлыбәян корткага, ай-һай дию юк инде!

→ Ахыры 13нче биттә.

Фазыловларның биш шатлыгы

ҮРНӘК

Фазыловлар гаиләсе өчен бу ел бигрәк тә үзенчәлекле. Ай ярым элек кенә аларның игезәк балалары Хәким белән Хания туды. Раил, Илназ һәм Ясминә берьюлы энеле дә, сеңелле дә булдылар.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

Рамил белән Гүзәлнең парлы тарихлары 2007 елдан башланган. Гүзәл ул вакытта химия-технология техникумында, ә Рамил 137нче техник училищеда укып торган булган. Икесе дә спорт түгәрәгенә йөриләр, Гүзәл волейбол, Рамил баскетбол командасында уйный. Танышуларына өч айлап вакыт үткәч, Рамил армиягә китә. Ел ярымнан әйләнеп кайта да Казан вертолет заводына эшкә урнаша. Ике айдан Гүзәл дә шул ук заводка эшкә бара. 2009 елда алар өйләнешәләр. Язылышу таныклыгын алганда Гүзәлгә – 20, Рамилгә 21 яшь була. Бүген инде алар биш бала тәрбияли.

– 28 яшьтә биш бала анасы булуыма күпләр шакката. Ә мин горурланып елмаям. Ирем дә, үзем дә балаларны бик яратабыз. Өебез балалар тавышыннан гөр килеп тора. Олы улыбыз Раил инде беренче сыйныфта укый. Илназга – биш яшь. Ясминәбезгә ике тулды. Әни булу авырмы дип сорыйлар. Авыр түгел, ә менә игезәкләрне үстерү ансат түгел икән. Тагын бер пар кул кирәк. Әле ярый каенанам Тәнзилә булыша. Аңа бик зур рәхмәт. Дүшәмбе иртән килә, җомга кич китә. Атна буе безнең белән. Ял көннәрендә ирем өйдә, ул булыша, ике көн буена әни бездән ял итеп тора, – дип көлә Гүзәл.

Фазыловларның икенче уллары Илназ бик тере бала. Әнисе дә аның турында, ул иң беренче булып йокыдан тора, иң беренче булып утырып ашый. Ризыкны сайланмый, барысын да яратып ашый, ди. Илназ яңа туган энесе белән сеңлесен дә карарга булыша. Уенчыклар да күрсәтә, урамга чыгарга җыенганда киемнәрен дә китереп бирә, бәбиләр тирәсендә дә гел ул кайнаша. Олы уллары Раил бик пөхтә, чисталыкны ярата ди. Энесе белән сеңлесе ашарга сораса, күмәч кисеп, ак май сылап, кулларына тоттыра. Ясминә исә – әти кызы. Әтиләре эштән кайтуга ук, «Әти», – дия-дия, артыннан бер дә калмый ияреп йөри. Балаларның барысы да әтиләренә охшаган, хәтта каннары да барысының да 3 (+) нче төркем икән.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Гүзәл тегәргә, бәйләргә ярата. Балаларның өсләрендә ул теккән, бәйләгән киемнәр. Урын-җир кирәк-яракларын да, Яңа елга маскарад костюмнарын да үзе тегә. Шуның белән гаилә бюджетына күпмедер экономия ясала.

Фазыловлар йорт сатып алганнар. Ел саен кыш көне бакчаларында күп итеп кар өеп, тау ясап куялар. Айга бер тапкыр зур бәлеш пешереп, дәү әти һәм дәү әниләрен кунакка чакыру традициясе дә бар аларда.

– Балаларны яратырга кирәк. Гаиләдә балалар күбрәк булган саен, бердәмлек арта гына. Гаиләбезнең ныклыгы әти-әнидән килә. Алар безгә һәрьяктан үрнәк. Аларның тормышларына тиңләшеп яшибез, ныклы нигез булдырырга тырышабыз, – ди күп бала атасы Рамил.

ШАККАТАМ

Акылсыз көндәлек

Мәктәптә укыганда аеруча кызлар арасында истәлек дәфтәрләре язу киң таралган иде. Кулдан кулга йөреп таушалып беткән, хәтер-хатирәләр тулы мондый көндәлекләр күпләрдә бүген дә сакланадыр әле.

Хәзер исә балалар мондый истәлекләр язып азапланмыйлар, көндәлек-блокнотларны кибеттән генә сатып алалар. Ул көндәлекләрдә барысы да язылган, ясалган, бизәлгән, биремнәр бирелгән. Аларның ниндиләре генә юк, хәтта ашый торганнарына кадәр бар.

Канада рәссамы Кери Смит блокнотында нәкъ менә кәгазь битен чәйнәргә кушылган бирем бар. Көндәлекнең исеме дә үзенчәлекле «Мине юк ит!». Карап торышка гади генә кәгазьдән, аклы-каралы гына бизәлгән бу блокнот миллионлаган тираж белән таралган. Безнең илдә дә бар ул. Казанда мин аны гадәти булмаган бүләкләр сатыла торган сәүдә ноктасында күрдем. Бәясе – 600 сум. «Бу китап иҗатны үстерә. Креативлыкны син бар нәрсәне җимерүдә күрерсең, әзерлән, синең тормышың тагын да акылсызга әйләнәчәк», – дип язып куйганнар беренче битендә. Гаҗәпләнгәнемне күреп, сатучы: «Бу бик үзенчәлекле бүләк. Баланы гадәти булмаганча уйларга өйрәтә», – дип, блокнотны мактарга тотынды. Битләрен актарам. Тәкъдим ителгән биремнәрнең мәгънәсезлегеннән исең китәрлек: төсле конфет аша да телең белән бу биткә рәсем ясa; кәгазьне яла; бу биткә пычрак сыла; монысы белән юылмаган машинаны сөртеп ал; бу блокнот белән көтелмәгән хәл кыл; үлгән бөҗәкләрне җый; аяк белән бас; бу биткә каһвә түк... Бу блокнот балада ничек креативлык уятырга мөмкин, дип сатучыга карыйм.

– Без бит кечкенәдән балаларны китапны сакларга кирәк, ертырга ярамый дип өйрәтәбез. Бу блокнот кагыйдәләрне бозарга ярдәм итә. Бала бу дәфтәр белән нәрсә тели – шуны эшли: ташлый да, суга да чылата, пычракка да батыра. Кыскасы, хисләренә ирек бирә, – ди сатучы.

Китапның кадере болай да бетә барган заманда, янган утка ялкын өстәү генә түгелме икән бу. Җимерү – иҗат була аламы?

Психолог Люция Закирҗанова исә моны маркетинг төре, реклама алымы дип аңлата.

– Балаларга кечкенәдән нәрсәне дә булса җимереп карау кызык тоела бит. Үсә-үсә, балада билгеле бер шаблоннар формалаша. Бу блокнот шул шаблон кагыйдәләрне җимерүгә корылган. Әйе, бала агрессиясен ничек тә чыгарырга тиеш. Психологик тренинглар вакытында да әлеге блокноттагы биремнәргә охшаган кайбер алымнар кулланыла. Әмма моның өчен фәлән суммага блокнот сатып алырга кирәк түгел. Гади кәгазь бите дә җитә. Әхлаклылык, креативлык ягыннан блокнотның уңай ягын күрмим. 2000 нче еллардан соң туган балалар болай да үзенчәлекле. Тамаклары тук, өсләре бөтен дигәндәй, күбесе җитеш тормышта яши. Тик менә яхшы белән начар арасындагы чикләр генә югалган. Көчләре күп, энергияләре ташып тора. Шул ук вакытта акны карадан төгәл аеру сизелми, «ярамый» дигәнне кабул итмиләр. Алар өчен креатив булу – текәлек билгесе. Креативлыкның асылы, әлбәттә, җимерү була алмый. Ул блокнотта уйландыра торган, психологик яктан файдалы биремнәр булса, күпкә отышлырак булыр иде. Эшләгән гамәлләрең өчен җаваплылык хисен тою булырга тиеш. Ничек кенә булмасын, без җәмгыятьтә яшибез икән, һәркем үзен билгеле бер кысаларда тотарга мәҗбүр. Мәктәптә укучыларның таушалган дәфтәрләре, тышланмаган дәреслекләре еш кына күзгә чалына. Димәк, китапларга сак караш кечкенәдән формалашмый. Гомумән, күп нәрсә тәрбиядән килә. Ата-аналар балаларга яхшыны яманнан аерырга өйрәтсәләр, мондый блокнотлар гына аларның фикерен үзгәртә алмаячак, – ди психолог.

Язманы әзерләгәндә, элеккеге заманнан килгән шаярулар искә төште. Подъездларга язу, асфальтка рәсем ясау, парта асларына сагыз ябыштыру, чәйнәлгән кәгазьне дәрестә линейка белән аттырып утыру, укытучы урындыгына кнопка кую... Чит илдән кергән блокнотлардан өйрәнмичә дә, акылсызлыклар җитәрлек ләбаса бездә.

Эльвира МОЗАФФАР.

МАТУР МИЗГЕЛЛӘР

Ана белән ул

Теш табибына килдем. Миннән алда коридорда бер ир-ат тора иде инде. Шул тиклем борчыла, арлы-бирле йөренә. Мин аны күзәтәм. Ир-атларны куркак диләр, дөрес инде, дип уйлыйм күңелемнән. Кара инде бу ирне, бер урында басып тора алмый. Кем курыкмый, аны бөтен кешегә күрсәтергә димәгән бит инде.

Мин күңелемнән әлеге ирне битәрләгән арада, табиб бүлмәсеннән шәфкать туташы эндәште:

– Әниегезне алыгыз!

Теге ирнең кулларын җәеп, очып кереп киткәнен күрсәгез! Ана каз бәпкәләре янында ничек гөрелди, бу ир дә әнисен табиб яныннан нәкъ әнә шулай итеп алып чыкты.

– Бүген әниемнең туган көне, аңа 84 яшь тулды, – диде ул ишек төбендә торучыларга.

Әнисе сөбханалла әле. Бик җитез татар әбисе, улы белән рәхәтләнеп татарча сөйләшәләр. Ул арада күзге янына барып үзен дә карап килде. Мин инде хәзер анадан күземне алмадым: менә бит нинди ул тәрбияләгән. Ана белән ул күңелгә көне буена җитәрлек җылы биреп киттеләр.

Сәнгать әсирлегендә

Айдар Фәйзрахманов концерты бара. Шигърият, җыр, биюләр... Күңелнең иң нечкә кыллары тартылды, уянмаган бер генә күзәнәк тә калмагандыр. Концерт бетте. Халык, аягүрә басып, кул чаба. Артистлар инде әллә ничә тапкыр сәхнә алдына килеп баш иделәр. Халык һаман урыныннан кузгалмый, беркем беркая ашыкмый. Хәтта фойега чыккач та, гардеробка тезелмәделәр, киресенчә, үзара хисләре белән уртаклаштылар. Әйт инде син менә шуннан соң халыкка югары сәнгать кирәкми дип. Сәнгате чыннан да югары булсамы?!

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА.

АШ БУЛСЫН

Гөлчәчәк Фәтхулловадан гади генә бисквит

Дүрт йомырка, бер стакан (ярты стакан да җитә) шикәр комы, бер стакан он, бер чеметем ванилин

Йомырканың агын сарысыннан аерабыз. Агын миксер белән акрын гына күпертә башлыйбыз. Ак төскә керә башлагач, шикәр комын акрынлап кашыклап салабыз. Ап-ак төскә кергәнче, куерганчы-күпергәнче, бик яхшылап болгатабыз. Ак крем сыман бер масса хасил була. Аннары тугланган йомырка сарысын йомырка агына кашыклап салып, миксер белән болгатуны дәвам итәбез. Массабызны яхшылап болгаткач, миксерны бер читкә алып куябыз. Ванилин һәм он өстәп, төерләре беткәнче, кашык белән сак кына астан өскә болгатабыз. Камырыбыз әзер. Табабызны майлыйбыз йә булмаса пергамент кәгазе җәеп, аның өстенә камырыбызны агызабыз. 200 градуслы кызган мичкә куеп, бисквитыбызны пешереп алабыз. Пешеп чыкканын шырпы белән тикшереп карыйбыз. Шырпы коры булса, бисквит пешкән дигән сүз. Алып суытып, тортлар, пирожныйлар ясыйбыз йә булмаса эретелгән шоколад белән бизәп, чәй янына бирәбез. Шунысын истә тотыгыз: газ мичен 25-30 минут ачмаска кирәк. Ни өчен дисәгез, аны ачкан очракта, бисквитыбыз күтәрелгән җирдән төшеп китәргә мөмкин. Бу рецептта чәй содасы, разрыхлитель салынмый.

КИҢӘШ САНДЫГЫ

ОСТА КУЛЛАР



ФАЙДАЛЫ

Борай ярмасы кире кайта

Борай элек-электән кешелек дөньясына мәгълүм. Әби-бабайларның көндәлектә кулланган борай ярмасы соңгы елларда популярлаша башлады. Интернетта аңардан бәлеш пешерү рецептлары да еш очрый. Борай бәлеше бик тәмле дә, файдалы да. Бу ярмада унсигез төрле аминокислоталар, фосфор, кальций, магний, цинк, тимер кебек микро һәм макроэлементлар бар. Аксымга байлыгы ягыннан ул тавык йомыркасын да уздыра. Гади бодайга караганда борайда тимер, протеин, В төркеме витаминнары күбрәк. Диетологлар да борайның файдасы күп булуын әйтә. Аз калорияле. Ябыгырга теләүчеләр аны рационнарына курыкмыйча кертә ала. Табиблар йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан җәфаланучыларга, ашкайнату системасы начар эшләгәннәргә шулай ук борай ашарга куша. Иммунитетны ныгыту өчен дә борай ашарга кирәк. Анда клетчатка да күп, шуның белән ул шикәр һәм холестерин күләмен көйләп торырга ярдәм итә.

Шунысын да әйтергә кирәк: борай минераль ашламаларга бәйсез, ягъни ул үскән басуга гербицидлар, инсектицидлар бөтенләй кертелми. Шуңа да ул экологик яктан чиста продукт санала. Европада борайдан әзерләнгән ризыклар моннан 10-15 ел элек кенә сатыла башлаган. Алар аны «Сәламәт туклану» дип аталган кибетләрдә саталар. Борайны америкалылар да киң куллана башлаган: боткасын пешерәләр, ашка салалар. Голландиядә аннан пешерелгән ипи бик популяр.

БАКЧАЧЫГА

✓ Томат орлыгын март уртасы-ахырында чәчәбез. 55-70 көн үткәч (кырау төшү куркынычы беткәч), ачык грунтка утыртырга ярый.
✓ Баклажан орлыгын март уртасында чәчәбез. Ике яфрагы чыккач, аерым савытларга берәмләп күчерәбез. 60-70 көн үткәч, май ахырында грунтка утыртабыз.
✓ Болгар борычы орлыгын март башында чәчәргә киңәш итела. 70-80 көн узгач, ачык грунтка утыртабыз.
✓ Кыярны апрель ахырында чәчәргә кирәк. Өч-дүрт яфрагы чыккач (бер ай) утыртасы. Теплица булганда, бер өч атна иртәрәк тә утыртырга була.
✓ Брокколи. Төсле кәбестәне март уртасында чәчәбез. 35-40 көн үткәч, грунтка күчереп утыртабыз.
✓ Иртә өлгерешле кәбестәне март уртасында чәчәбез, май уртасында-ахырында (50 көн тирәсе) грунтка күчерәбез.
✓ Урта өлгерешле кәбестәне исә апрель ахырында чәчеп, үсентене бакчага май ахырында (40 көн) утыртабыз.
✓ Соң өлгерешле кәбестә апрель уртасында чәчелә, май уртасы-ахырында (35-40 көн) грунтка күчерелә.
✓ Кабакны апрель ахыры-май башында чәчәргә, ике-өч яфрагы күренгәч, май ахырында грунтка чыгарып утыртырга.

АШЫГЫЧ ЯРДӘМ

Канны сыегайта торган продуктлар

Инфаркт, инсульт, тромбофлебит, кан тамырларының варикоз киңәюе... Әлеге авыруларның уртаклыгы нидә? Алар барлыкка килүнең бер сәбәбе – канның куе булуы. Димәк, аны сыегайтырга кирәк. Ә моның өчен рационны үзгәртү киңәш ителә.

- Су күбрәк эчегез.
- Зәйтүн һәм җитен маен кулланыгыз.
- Суган, сарымсак, лимон, банан, помидор, көнбагыш, чөгендер ашагыз.
- Какао һәм шоколадның да файдасы зур.
- Балык, балык маен куллануны гадәткә кертегез.
- Томат согы эчегез.
- Имбир, кура җиләге, кара җиләк, мүк җиләге, чия, гөлҗимеш, кара миләшне сезонда күбрәк ашагыз.
- Спиртлы эчемлекләр эчүне, тәмәке тартуны, тоз күп куллануны ташлагыз.

ХУҖАБИКӘГӘ

Җиләк-җимештән ассорти

МӘЛЕНӘ–ӘМӘЛЕ

Чүлмәктәге кыяр

Бакчачы Ирина Иокша кыярларын биш литрлы пластик шешәгә утырта. Аларның өске һәм аскы өлешләрен кисеп ала да җиргә 5 см тирәнлектә батырып куя. Эченә туфрак өстәп, үсентене шунда утырта. Болай иткәндә, кыярның тамырлары чуалып бетми, тукландыру да, су да үсемлекнең төбенә китә. Сез дә сынап карагыз.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА әзерләде.

Казан вертолет заводы тарихында беренче хатын-кыз баш металлург Марина Ожегова: «Баштарак үземне космоска очкан Валентина Терешкова кебек хис итә идем», – дип елмая. Металлургия өлкәсендә, гадәттә, ир-атлар хезмәт итсә дә, әңгәмәдәшем бу һөнәрне сайлавына һич кенә дә үкенми. Аныңча, һәр эш үзенчә кирәкле. Хәер, ул һөнәрләрне ир-ат, хатын-кызныкына бүлми: «Белемнәрне камилләштерү өчен барлык мөмкинлекләр тудырылган заманда һәркем теләсә кайсы өлкәдә эшли алыр иде» – бу аның кагыйдәсе.

Эльвира МОЗАФФАР

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

БЕРЕНЧЕ

Героебыз – нәфис гәүдәле, мөлаем, зәвыклы хатын-кыз. Металлург дигән каты, авыр сүз аңа бик туры килеп тә бетми кебек. Хәер, вертолет заводында металлургия төшенчәсе дә үзгәрәк. Биредә металлны эшкәртү, химик процесслар, гальваник һәм химик япма, кою, эретеп ябыштыру, буяу, җыю кебек эшләр белән шөгыльләнәләр. Ничек кенә булмасын, хезмәт җиңелләрдән түгел. Заводта 33 ел эшләү тәҗрибәсе Марина ханымны күп нәрсәгә өйрәткән.

Казан дәүләт университетының химия факультетын тәмамлаган кыз 1984 елда, юллама белән, Казан вертолет заводына эшкә килә. Әтисе Анатолий Осипов – бик сәләтле, актив инженер-конструктор, үзе дә гомеренең күп өлешен заводка багышлаган кеше.

– Совет заманыннан ук зур оешмалар үзенә бер дөнья булган. Эшче һөнәр ияләре өчен биредә аерым тормыш гөрләгән. Әти завод белән бәйле вакыйгаларны еш сөйли иде. Киңәшләре дә этәргеч биргәнләр. Завод ул чакта тотрыклылык сүзе белән тәңгәлләштерелде. Әти рәссам да иде әле. Завод хуҗалык кирәк-яраклары, сувенирлар чыгарган вакытта да эскизлар ясауда аның өлеше зур булды. Бу сәләт нәселдән күчкән, күрәсең, төсләр белән эшләү миңа да ошый. Мәктәптә, университетта да гел стена газеталарын бизи идем, – ди әңгәмәдәшем.

Хезмәт юлын инженер-технолог вазифасында башлаган белгеч баштарак гел буяулар белән мәшгуль була. Сыйфатны яхшырта торган махсус эмальләр, катлаулы эмблемалар өчен үзенчәлекле төсләр ясый, буяуларны катнаштыра. Биш ел буена завод үзәк лабораториясен җитәкли. Бу өлкә үзенә бер зур мәктәп була.

– Беркайчан да җитәкче булырга омтылмадым. Гадәтем: барысын да җиренә җиткереп үтәү, төгәл, дөрес башкару. Һәр проблеманы молекулага кадәр таркатып чишәргә тырышам. Чишелмәгән мәсьәлә минем өчен кроссворд сыман. Уйлыйм. Җавабын эзлим. Һәрчак яңалыкка өйрәнәм, – ди Марина Ожегова.

Аның өстендә зур җаваплылык. Ул үзәк лаборатория эшчәнлеген, кою, эретеп ябыштыру, буяу процессларын күзәтә, тикшерә. Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру, нәтиҗәлелек еш кына сыйфат белән бәйләнгән. Казан вертолетлары дөньякүләм дәрәҗәдә танылу алган, сынатырга ярамый. Завод 77 ел эшләү дәверендә 100ләп илгә 12 меңнән артык Ми-4, Ми-8, Ми-14, Ми-17, «Ансат» вертолетларын һәм аларның модификацияләрен җитештереп саткан. Татарстанның иң алдынгы машина төзелеше предприятиесе дөньякүләм стандартларга нигезләнеп эшли. Замана белән бергә атларга туры килә. Заводта инновацион проектлар, күп кенә социаль программалар тормышка ашырыла. Оешма «Россия вертолетлары» холдингында иң алдынгы урыннарның берсен били.

– Безнең эштә тәҗрибә зур роль уйный. Аны вакытында һәм дөрес куллану да кирәк. Еш кына мәсьәләнең чишелешен табып, хәлиткеч карарлар кабул итәргә туры килә. Дәвамчыларыбыз булуы да сөендерә. Бүлеккә яшьләр күп килә, – ди әңгәмәдәшем.

Баш металлург булса да, Марина ханым беренче чиратта – хатын кыз, ике баласының кадерле әнисе, гаилә учагын саклаучы. Яраткан бәйрәме дә – Халыкара хатын-кызлар көне. Буш вакытларында ул бассейнга, спорт секцияләренә йөри, үзен гаиләсенә багышлый. Мәктәп яшеннән ук кул эшләрен үз иткән.

– Хәзерге эшем дә чигү, тегү, бәйләүне хәтерләтә сыман. Шул ук билгеле бер технология, яңалык тудыру, иҗади фикерләү, модель ясау, сызымнар... Бары тукыма урынына металл гына, – дип елмая үзе.

Нинди генә авыр вакыт булмасын, һәр нәрсәдә дә уңай якларны күрә белергә кирәк, дигән шигарь белән яши.

– Моңаерга, сагышланырга ярамыйм. Елмаеп яшик. Һәркемнең күңелендә мәңгелек яз булсын, – ди.

ИРЛӘР КАРАШЫ

Данил Сәфәров:
«Хатынның бәхете – ирдән»

«Замана хатын-кызы нинди ул?» – дисезме. Әлбәттә, төрлесе бар. Әмма бер категория асыл зат бигрәк замана галәмәте инде. Һәрвакыт алда булырга теләүче, үзен көчле хис итүче, ирләр белән ярышучы кызлар турында әйтүем.

Танышларым-дусларым арасында кияүгә чыга алмаган 25-35 яшьлек кызлар күп. Берсе дә төшеп калганнардан түгел. Киресенчә, бала тәрбиялисе булмагач, бар көчләре белән карьера ясыйлар. Үзләре ипотекага фатир алган, машина йөртәләр, ирләр игътибары да юк түгел, әмма ир юк. Чөнки ир аларга кирәкми дә. Ирдән таләп ителә торган бар эшне алар үзләре башкара. Мондый кызлар кияүгә чыкса, аларга тагын да авыррак булыр дип уйлыйм. Ни өчен дигәндә, дилбегәне ир белән бүлешәсе килмәс. Инде ничә ел дилбегә тотып ияләнелгән бит. Көчле хатыннан ир дә курка. Барысы да бер-берсенә бәйләнгән, кыскасы.

Хатын-кыз – табигатьтән көчле зат. Экстремаль ситуациядә ир түзми, хатын түзә. Тарихта моңа дәлилләр бик күп. Бүгенге хатыннарның гаиләдә баш булуларына да тарихи аңлатма бар. Совет заманында эчү модада иде. Ирләре хәмер белән мавыккан арада, гаилә дилбегәсе хатыннарга калды. Алар бу дилбегәне чарасызлыктан алды. Хәзер инде эчү дә модада түгел сыман, әмма бер биргәнне кире алу психологик яктан җиңел түгел. Хатын-кызның бәхете ирдән, диләр (ирнеке дә хатыннан аныс үзе). Чыннан да шулай. Карьерада зур уңышларга ирешкән кызлар тыштан ялтырый, эчтән калтырый. Эчтән бик бәхетсез алар. Кияүдә булып гаиләдә баш булырга мәҗбүр хатыннар да шул ук хәлдә. Замана хатын-кызының төп проблемасы – хатын-кыз була белмәүдә. Хатын-кыз ролен дөрес уйнамауда.

Ни өчен мин бәйрәм көнне акыл сатып утырам соң әле? Барлык асыл затны бәхетле итеп күрәсе килә. Шул гына. Һәр хатын-кызга хатын-кыз була белү бәхете телəп калам!

Данил Сәфәровтан хатын-кызларга 10 киңәш

1. Ирләрегез белән ярышмагыз, дилбегәне үз кулыгызга алырга тырышмагыз.
2. Гаилә бюджетын ирегез алып барсын.
3. Ирегездән күбрәк акча эшләргә омтылмагыз.
4. Квартплатаны һәм башка түләүләрне үзегез түләмәгез.
5. Машина йөртсәгез дә, техосмотр-фәләннәрен ирегез башкарсын.
6. Ирегезне мактагыз, аңа соклануыгызны үзенә әйтегез.
7. Ирләрегезнең мавыгуларын хөрмәт итегез (спорт, ау, балык тоту, корал ярату, дуслар белән очрашу һ.б.).
8. Дус кызларыгызга һәм әниегезгә ирегезне беркайчан яманламагыз.
9. «Әтиегез ни әйтер» дип, балаларыгыз каршында әти авторитеты булдырыгыз.
10. Алдагы тугыз пунктның барысы да ирләр турында. Әмма хатынның бәхете ирдән бит.

КӨЧЛЕ КӨЧСЕЗЛӘР

Хатын-кызны көчсез зат, дибез. Әмма әлеге сүзләр бүгенге геройларыбызга бөтенләй дә диярлек кагылмый. Гаиләләрендә, ирләре янында бәлки шулайдыр да, әмма эштә түгел. Монда алар ир-атлар белән бер дәрәҗәдә, чөнки тормыш юлларында сайлаган һөнәрләре – чып-чын көчле затларныкы. Бәйрәм уңаеннан без сезне дә Татарстанның әнә шундый иң тырыш, көчле ханымнары белән таныштырырга булдык.

Зөһрә САДЫЙКОВА

УРМАНЧЫ

Татарстанның бердәнбер хатын-кыз участок урманчысы Наилә Сафиуллина Нурлат районының Мамык урман хуҗалыгын 2008 елдан бирле җитәкли. Бу өлкәдәге гомуми эш тәҗрибәсе исә 34 елга тулган. Маяк итеп ал-

ган һөнәренең ир-ат эше булуы гына туктатып калмаган бу көчле ханымны, сайлаган юлында зурдан-зур уңышларга да ирешкән. Агачларны үзенчәлекле утырту алымын куллану нәтиҗәсендә, хуҗалыкның урман культуралары 745 гектарга арткан. Туфрак авыруыннан саклау, авыл хуҗалыгы кырларының уңдырышлылыгын арттыру максатыннан, кар саклау өчен урман полосалары барлыкка китерелгән һәм иң алдынгы ысуллар кулланып, ерымнарга агачлар утыртылган. Наилә ханым эшләгән дәвердә Нурлат районы урман фондында 7116 гектар мәйданда урман культуралары һәм 240 гектарда саклау үсентеләре барлыкка килгән. Хәзерге вакытта урманның гомуми мәйданы – 17 мең гектар.

– Урман – минем икенче йортым, чөнки аның белән бөтен тормышым бәйләнгән. Мин Бутаих урман бистәсендә туып-үстем. Табигатьнең әлеге бай бүләген саклау өчен сайланган һөнәремдә әнә шуның да зур тәэсире бар. Лубян урман хуҗалыгы техникумын тәмамлаганнан бирле шушы өлкәдә эшлим. Эш тәҗрибәм 30 елдан артып китте инде. Минем күзәтчелегем астында урмандагы агачларны корткычлардан һәм законсыз рәвештә кисүчеләрдән саклауга зур игътибар бирелә. Урманда янгыннар килеп чыкмасын өчен дә зур тырышлык куябыз. Моның өчен язын төрле чаралар күрәбез. Янгын куркынычы булган вакытларда аеруча авырга туры килә. Аллага шөкер, соңгы ун елда урманнарыбызда бер тапкыр да янгын чыкмады, – дип горурлана урманчы ханым.

АҢА ТИМЕР БИЛ БӨГӘ

Әгерҗе районының Тирсә авылында яшәүче Любовь Сәлимова менә инде 20 ел токарь булып эшли. Төзекләндерелә торган техника өчен детальләр әзерли ул. Моңа кадәр складта җыештыручы булып эшләгән ханымның тормышы техникага булган мәхәббәте аркасында бөтенләй башка якка борылыш алган.

– Токарь һөнәренә мине өлкән ярдәмчеләрем һәм остазларым өйрәтте. Әле бүген дә үз кулларым белән эшләгән беренче гайканы хәтерлим. Ул яхшы гына килеп чыккан иде, шуннан соң китте инде чөй, вал, төрле күчәрләр. Эшемне бик яратам. Теләсә нинди машина-тракторны, КАМАЗны, чәчкечне ремонтлап куя алам. Мине аеруча шоферлар ярата инде (*Көлә.* – **Авт.**). Бер-

сенә – шайба, икенчесенә болт яки гайка ясарга кирәк... Безнең эштә иң мөһиме – сабырлык һәм игътибарлылык. Бераз гына ялгышлык китсә дә, деталь эшкә яраксыз була. Профессиям буенча мин – аш-су остасы. Шуңа күрә эшемне гел кулинарлык белән чагыштырам. Алар кухняда иҗат итсә, без – кырда. Аерма шунда – аш-су бүлмәсендә фантазиягә зур урын бирелсә, монда бик зур төгәллек кирәк, – ди яңа танышым.

Любовь ханым турында, теләсә нинди токарь ир-ат аның осталыгы алдында баш ия, диләр. Шуңа күрә хатын-кыз өчен гадәти булмаган һөнәр сайлаган апаны һәр җирдә дә хөрмәт итәләр.

ЙӨК ТАШУЧЫ ВЕРОНИКА

Социаль белем бирү академиясе студенты Вероника Пичугина исә урып-җыю чорында әтисенең төп ярдәмчесе – ул «ЗИЛ» автомобилендә ашлык ташый. Шуңа күрә 21 яшьлек Казан студентының җәйге яллары туган ягында

– Югары Ослан районы Макулово авылында уза. Вероника – булачак икътисадчы.

– Мин мәктәпкә укырга кергән елдан башлап апаларым белән бергәләп әтигә булыша идем. Кырда ашлык араладым. Ә кулыма таныклык алу белән үк йөк машинасына утырдым. Әтием Валерий – комбайн йөртүчесе. Ул бик максатчан кеше, бөтенесенә дә үз тырышлыгы белән иреште, шәхси предприятиесе бар. Җәй көне без барыбыз да гаиләбез белән кырда. Апаларым Казанда яшәсәләр дә, эшнең иң кызган чорында алар да авылга кайтып, әтигә булыша. Әниебез ашарга пешерә. Ирем дә шушында ук хезмәт куя. Миңа үз эшем ошый. Зур шәһәр минем өчен түгел, күңелем авылга тартыла. Дөрес, быел җәй эшләп булмас инде. Шушы көннәрдә генә әни булдым, – диде Вероника.

«КОМБАЙНЧЫ ВЕНЕРА

«Чулман»-«Органик Групп» җәмгыятендә эшләүче (Минзәлә районы Югары Тәкермән авылы) Венера Бикмөхәммәтова да сер бирә торганнардан түгел. Ул – «Дон-1500» комбайнында эшләүче комбайнчылар арасында лидерлыкка чыккан ханым. Венера көзге урып-җыю чорында кырда тир түксә, башка вакытларда машина-трактор паркы хуҗалыгында бензин салып торучы булып эшли.

Комбайн кадәр комбайн руле артына утырганчы, башта иренә ярдәм иткән. Трактор-машина йөртүче кенәгәсен исә 2007 елда алган.

– Комбайн йөртергә сәләт-

ле икәнлегемне һәм аның нечкәлекләрен ир-атларга караганда да яхшырак белүемне исбатлар өчен шактый тырышырга туры килде әле миңа. 2010 елда кырдагы эшләр төгәлләнеп, бер атна үткәч, кызымны алып кайттым. Урып-җыюның соңгы көненә кадәр эшләдем. Эш җиңел түгел, әлбәттә, пычрак, тузанлы, әмма иң борчыганы – балаларымны сирәк күрәм, аларга бик аз вакыт кала, – ди дүрт кыз әнисе Венера.

«ГАДӘТТӘН ТЫШ ЭШ ЭШЛӘМИМ»

Комбайнчы туташ Миләүшә Мостафинаны Тукай районында гына түгел, бөтен республикада беләләр. Чөнки ул – яшь комбайнчылар арасында үт-

кәрелгән «Кешене хезмәт данлый» республика конкурсында җиңү яулаган кыз. Бу уңышыннан соң аны имтиханнарсыз гына Казан аграр университетына укырга алганнар. Аңа кадәр ул программистлыкка укып чыккан булган. Миләүшә комбайнчы һөнәрен очраклы рәвештә генә сайламаган. Әтиләре Марат Мостафин да хуҗалыкта эшли. Башта 14 яшьлек кыз аңа ярдәмче булып йөргән, 19 яшендә үзе дә штурвал артына утырган. Бишмунча авылында яшәүче гаиләнең өч баласы да – әти-әниләренең ныклы ярдәмчеләре. Миләүшәнең сеңлесе Зәлидә дә апасына ярдәм итә, киләчәктә үзе дә комбайнда эшләргә уйлый.

– Мин 3нче сыйныфтан ук әтигә булышып килдем. Башта трактор, аннан соң комбайн ярдәмчесе булдым. Эшемне яратып башкарам. Әмма мин үземне ниндидер гадәттән тыш эш башкарам дип санамыйм. Кырда эшләү рәхәтлек бирә, – ди ул.

БРИГАДИР НАДЕЖДА

Нурлат районының Богдан авылында яшәүче 60 яшьлек Надежда Федотова машина ремонтлау остаханәсен җитәкли. Сигезьеллык мәктәпне тәмамлагач, тракторчы булырга укыган. Аннан соң да озак еллар шул сайлаган һөнәренә тугры калып, колхозда хезмәт иткән. Тракторчы, бригадир булып эшләгән апаның авыл хуҗалыгындагы эш стажы 41 елга тула.

– Эшкә иртә таңнан киләм, өйгә кич кайтам. Хезмәтемне яратам, авырлыгына да күнеккәнмен инде, сизелми дә. Хәзерге вакытта да эшебез тыгыз – язгы кыр эшләренә әзерләнәбез. Машиналарны төзекләндерәбез, – диде Надежда Евгеньевна.

ТРАКТОРЧЫ ГАЛИЯ

Биектау районының Чыпчык авылында яшәүче 69 яшьлек Галия Камалова да – уникаль шәхес. Озак еллар ул йөк машинасын да, тракторын да йөрткән, «Ашыгыч ярдәм» машинасы руле артына да утырган.

– 1993 елда Таҗикстаннан кайттым да 2000 елга кадәр «Бөреле» совхозында йөк машинасын йөрттем. Аннан соң Чыпчыкка кайтып, МТЗ һәм Т16 тракторларына утырдым. 2013 елда куллар авырта башлагач, туктап, дәваланып алырга туры килде. Бераздан күңел түзмәде, барыбер эшкә чыгып, «Ашыгыч ярдәм» машинасын йөрттем. Бүген дә кул кушырып өйдә утырганым юк – оператор булып эшлим. Эшләремнең берсен дә авыр бул-

ды дип әйтә алмыйм. Дөрес, тракторым гына искерәк иде. Шуның белән бераз җәфаланырга туры килде эшләгән елларда. Анысын да үзем төзекләндерә идем. Ир-атлар да ярдәм итте. Аларның һәрберсе дә миңа хөрмәт белән карадылар, – ди Галия апа.

КУНАК БҮЛМӘСЕ

Салават Фәтхетдинов:

«Популярлык миннән мәңге китмәячәк»

«Телне, динне һәм милләтне бары тик язучы белән җырчылар гына саклап кала ала. Башка юл юк. Бу – татарларның да, башкортларның да уртак проблемасы», – дип сүз башлады ул. Уфада Салават Фәтхетдиновның Башкортстанда узачак концерт туры уңаеннан тәүге матбугат конференциясе узды. Җырчы түгәрәк өстәл артында ике сәгать дәвамында төрле темаларга ачыктан-ачык әңгәмә корды.

Зоя СОЛОШИНА

– Уфада матбугат конференциясе уздыруыгыз халыкны сискәндереп куйды. «Башкортстанга күченеп кайтмакчы икән» дигән имеш-мимешләр халыкта тиз арада таралды.

– Очрашу шушы сораудан башланырга тиеш иде дә. Үзегез күреп торасыз, замана үзгәрә: бар әйбер дә интернетка күчте, хәтта хәзер билетларны да аннан гына сатып алабыз. Әмма өлкән буын әлеге технологияләрне куллана белми, алар газета укырга, телевизор карарга ияләнгән. Ә концерт туры хакында аларның да хәбәрдар булуын, залларымның тулы булуын телим, чөнки тамашачыга әйтәсе сүзләрем бик күп. Спектакльне хәтерләткән гыйбрәтле концерт программабызда күп сорауларга җавап табарга була. Гыйбрәтле, тәрбияле. «Кызым, сиңа әйтәм, килен, син тыңла» темасы да бар. Бүгенге көндә балалар әти-әниләре белән судлаша. Кая тәгәрибез без, башка сыймаслык хәл! Моңа багышланган аерым бер җырым бар. Мөмкин кадәр күбрәк кеше килсә иде. Шул хакта хыялланам. Концертыма, үз акчасын түләп, иң самими тамашачы килә. Аларны алдап булмый. Син аларны залга куып кертә дә, чыгара да алмыйсың. Шул кадерле тамашачымнан Ходаем аермасын иде.

Күченеп кайтуга килгәндә, мин елның бер аен – августын – Казанда яшим, апрель аен – Башкортстанда, ә калган айлар гастрольләрдә үтә. Ни өчен мин Казанда яшим, Уфада түгел? Безнең авылдан дүрт чакрым ераклыкта Куеда тимер юл станциясе урнашкан. Аннан ике якка китеп була: Казан яки Екатеринбург. Күрәсең, Казанга билет бәясе очсызрак булган, шунда киткәнмен дә. Уфага тимер юл юк, ә Стәрлетамакта укыганда, «ПАЗик»ларда йөреп туйган идем инде. Әле дә ул «ПАЗик»ларны күралмыйм. Эш кайда яшәвемдә түгел. Барыбер Уфада да, Казанда да концертлар саны планга күпме кертелгән, шул кадәр куела, аннан артыгы түгел.

– Үсеш алмаган, иҗаты туктап калган кайсы җырчыларны әйтер идегез? Сезне дә шундый киләчәк көтәдер дип борчылмыйсызмы?

– Башка җырчыларның иҗатын бәяләп утырырга хокукым юк. Кайчак миннән: «Ә кайсы җырчыны яратасың? Кемне тыңлыйсың?» – дип сорыйлар. «Үземне генә яратам», – дип җавап бирәм. Чөнки берсен әйтерсең, икенчесен онытырсың – ул үпкәләр... Чынында исә сәхнәбезнең төп өч җырчысы гына бар: Әлфия апа, Илһам абый, Фәридә апа. Һәм башкалар. Шул «башкалар»га мин үзем дә керәм. Ә хәзер кызык – яңа пәйда булган җырчыларны сәхнәгә: «Каршы алыгыз, яңа йолдыз!» – дип чакырып чыгаралар. Йолдызның яңасы, искесе булмый. Ул «йолдыз»ны ник тагалардыр? Мин әйтәм, бар йолдызлар җиргә төшеп бетте инде, хәзер йолдызлар өстеннән йөрибез. Җырчыга шулай «йолдыз» дип дәшкәч, ул: «Кара әле, мин йолдыз бит», – дип, ышана башлый. Андыйлар миңа укырга да күп килә. Әйе, бәләкәй чагында урындыкка басып җырлатканда күрше әбисе әйткән дә: «Син – йолдыз, җырчы буласың», – дип, адашып килеп керәләр... Аларны кайчак хәтта куып чыгарырга туры килә. Тавыш булмаса, башка җир белән җырлап булмый бит. Шуңа күрә беркайчан да «блат» белән берсен дә укырга алмадым. Талантларга ярдәм итәргә кирәк, алар ярдәмгә мохтаҗ, ә булдыксызлар – әрсез, үзләре танышын да таба, укып та чыга, сәхнәгә дә менә. Бу өлкәдә мин усалрак.

Популярлык миннән мәңге китмәячәк. Ул минем белән гомерлеккә, чөнки мин ат кебек эшлим, үз йөгемне ат кебек тартам. «Салават» эстрада театры – бүгенге көндә гастрольләрдә иң күп йөри торган төркем. Мактанып әйтүем түгел, бу, киресенчә, сәламәтлеккә тискәре йогынты ясый. Әллә инде берәр ел ял итеп торыйм микән дигән уйлар да бар – туктап торырга ярамый. Артист тормышы – бик катлаулы. Игътибар кимлегеннән бер югаласың икән, кире кайтмавың да ихтимал. Бер күтәрелгәнсең икән, шул урында кала белергә кирәк. Элек гастрольләрдән айлар буена кайтмый идек, ә хәзер биш-алты көннән әбиемне, балаларымны, оныкларымны сагынып кайтам. Әби дип Ләйсәнне әйтәм, өч оныгыбыз бар, чын әби инде ул.

– Соңгы «Татар җыры»нда катнашмавыгызны да тамашачы популярлыгыгыз төшү белән бәйләде.

– Әйе, беренче тапкыр катнашмадым. Беренчедән, тантана көне алдан ук үзара килешенмәде. Ә без инде алдан ук Мәскәүдә концертларыбызны билгеләгән идек. Концерт көне билгеләнгән икән, мин аны беркайчан да үткәрми калмаячакмын. Бик зур сәбәп булса гына күчерә алам. Үз гомеремдә ике-өч тапкыр гына күчерергә туры килде. Минем өчен гади тамашачы – иң изгесе, иң мөкатдәсе, иң кадерлесе.

Мине карарга дип, Башкортстаннан бер төркем тамашачы килгән. Көтеп утырабыз, диләр. Айдар, Хәния чыгыш ясаган. Хәзер мин чыгарга тиеш, ә юк... Элвин Грей! Һәм концерт тәмам. Шул минутта миңа килгән смсларның санын белсәгез! Ул шалтыратулар! «Кем гаепле, нигә син юк?» – диләр.

Тагын бер ялгышу бар әле. Янәсе, концерт тәмамлаган җырчы – иң популяры. Юк, алай түгел. Бу яшьтә минем хәзер бөтенләй концерт ахырына кадәр көтеп утырасым килми, килергә дә, тизрәк җырлап кайтып китәргә. Әмма оештыручылар: «Салават, әйдә ахырда гына, синнән соң бар тамашачы да кайтып китәчәк бит», – диләр. Юк кайтып китми ул, чөнки залда һәр җырчының үз тамашачысы җыелган.

«Татар җыры»на килгәндә, белмим, киләсе елда ничек булыр. Инде сөйләшүләр башланды. Иганәче була алам, кемгәдер премияне тапшыра алам, почетлы кунак була алам... Әмма башкача катнашасым килми.

Ул Элвин Грей дигәннәре!.. Татар телендә алай җырларга ярамый. Татар моңына хас пентатониканы бозарга кирәкми, милли җырлар аерылып торырга тиеш. Менә үзбәкләрне алыгыз әле. Нинди генә телдә җырламасын, үзбәк җырлаганын шунда ук аңлыйсың. «Салават абый, исәнмесез! Сезнең белән танышасым килә», – дип, смс язды ул Элвин Грей. Бәлки очрашып, ярты сәгать бергә-бер сөйләшеп, аңа шуны аңлата алыр идем дә.

– Гомер буена тугры булган дусларыгыз бармы? Еллар узу белән, дуслыкка карашыгыз үзгәрдеме? Ялгышмасак, кредит алган Исрафилов та – сезнең якын дусларыгызның берсе иде бит.

– Ул кешене хәзер телгә дә аласым килми. Ни өчен? Чөнки үзеңнән акылсыз кешегә акыл биреп утырган кешедән дә акылсыз кеше юк. Бу афоризмны үзем уйлап таптым. Соңгы арада аларны язу белән мавыгам. Китап итеп чыгару теләгем дә бар.

Дус дигән сүзне быелгы концерт программасына да керттем. Бу сүзне һәркемгә дә тагып булмый, кадерле сүз ул. Әйе, яхшы танышлар була, әмма чын дус берәү, икәү, өчәү генә ул, аннан да артыгы түгел. Мине бервакытта да «сатмый» торган ике дустым бар. Алар бер серемне дә башкага чыгып сөйләмәячәк. Аларга тулысынча ышанам.

– Салават Зәкиевич, сез нинди әти? Карап торышка бик усал һәм кырыс кебек. Балаларны тәрбияләү эшендә катнашасызмы, моңа вакытыгыз каламы?

– «Әти, шулай-шулай, нишлик?» – дип киңәшләшәләр. Дөресен генә әйткәндә, кызларымның ничек үскәнен күрми дә калдым. Рөстәм тугач, Ләйсән: «Хет улыңны үзең тәрбиялә», – диде. Ә хатыным – акыллы усал кеше. Ул минем иң якын киңәшчем. Җырларымны да иң беренче булып ул тыңлый, бәясен бирә. Ләйсәнсез бу тормышта бер нәрсә дә эшләп булмый.

Усал әти дигәндә, балаларны, яннарында булмасам да, контрольдә тотарга тырышам. Интернетка керәм, Рөстәмнең «онлайн» икәнен күрәм. Шундук шалтыратам, ачуланам. Ул инде: «Әле генә кердем», – дип, мине тынычландыра башлый. Минем өчен интернет, телефон чире – иң куркыныч әйберләрнең берсе. Безгә ул чир янамый, ә менә балаларны аннан саклап калырга кирәк.

– Улыгыз өчен бар юлларны да ачтыгыз, спортта да үзен тапты. Киләчәктә югарырак биеклекләргә мөстәкыйль ирешергә теләге югалмасмы?

– Бар уңышы да үз тырышлыгыннан, ә мин аңа ияреп кенә йөрим. Чөнки ярышларда балигъ булмаган катнашучы әтисе яисә әнисе белән булырга тиеш. Гастрольләр тәмамлану белән, тренировкаларга, ярышларга ашыгабыз. Нинди генә шәһәрләрдә булмыйбыз: Воронеж, Курск, Рязань, Мәскәү... Рөстәм белән бик горурланам. 16 яшьлек егетләр арасында 14 яшьлек улым Россия чемпионы булды. Автоспорттан тыш, хоккей белән дә шөгыльләнә. Бу өлкәдә дә осталыгы бар, тренерлар аның белән җитди шөгыльләнмәкче иде. «Нинди хоккей? Уку!» – диде әнисе. Безнең гаиләдә беренче урында – уку. Рөстәмнең укуы, өй биремнәре белән Ләйсән шөгыльләнә, дөресрәге, бергәләп укыйлар. Ләйсән бу өлкәдә бик мәгънәле, төпле, мин кысылмыйм.

– Гаилә темасын дәвам итеп. Кияүләрегездән уңдыгызмы?

– Элегрәк өлкәннәр еш кына: «Бала кайгысы күрергә язмасын», – дип әйтәләр иде. Ул вакытта бу «дежур» сүзләргә артык игътибар итми идем: бер колактан керә, икенчесеннән чыга. Бала проблемасы никадәр авыр булганын үзең бабай булгач кына аңлыйсың икән... Чирләсәләр дә борчыласың, уңышсызлыкларына көенәсең...

Ә кызларымның бәхетле икәнен күрәм, димәк, кияүләр әйбәт. Беренче кызымның өч баласы бар. Киявем бик тыныч. Лиана белән алар икесе дә бер төсле. Икесе дә диндә, җомга намазын калдырмыйлар. Бер-берсенә кычкырып та эндәшми торган матур парлар инде. Ә икенче кияү – башкачарак, чөнки анда кыз да шундыйрак. *(Көлә.)* Алинә биш ел Америкада, Голливудта укыды. Николас Кейдж классын тәмамлады. Аннан соң Төркиягә кайтып, анда телевидениедә эшләде. Бик күп телләр белә. Елына бер кайтып китә иде. Шул арада «проамериканский» әйберләре сиздерми калмый иде. «Сез дөрес сөйләшмисез», «Сез дөрес эшләмисез»... Мин инде аңа җавап итеп үземчә кычкырам, ул үзенчә фикерен әйтә. Әмма барыбер, Аллага шөкер, башта Төркиягә, аннары Татарстанга кайтарттык. Кияүгә дә чыкты. Җитди өлкәдә эш башлады. 2018 елда Казанда Футбол буенча дөнья чемпионаты узачак, ул шунда чит ил кунакларын каршы алу белән шөгыльләнәчәк. Әмма барыбер журналистика белән кызыксына. Бик күп белә. Күп белү дә әйбәт түгел. Кеше үзенә сендерә алган кадәр генә белергә тиеш. Артыгы кирәкми. Шуңа да ул күп әйбердән канәгать түгел, һәр нәрсәгә үз фикере бар. «Кызым, бу Америка түгел», – дип, үз урынына еш кына утыртып куям.

«Илһам беркайчан да, җырчы булам, димәде»

Зәй районына сәфәребез вакытында очраклы рәвештә генә легендар җырчыбыз Илһам абый Шакировның апасы белән таныштык. Дүрт-Мунча авылы аша узганда, безне озатып йөрүче районның мәдәният бүлегендә эшләүче Кәүсәрия Кузнецова: «Бу авылда Илһам Шакировның апасы яши», – дип әйтеп ычкындырды. Шунда ук юлдашларыма карап куйдым. Күзләрдә очкын барлыкка килде, авызлар ерылды. Аңлашыла инде, Зәйнәп апа Гыйльметдинова белән һичшиксез танышып чыгарга кирәк иде. Вакыт ягы кысан булса да, очрашасы кешеләр көтеп торса да, биш кенә минутка дия-дия, Зәйнәп апаның өенә уздык.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА,
Зәй

Аның турында, ул үзе дә бик матур итеп җырлый, дип, юлда барганда ук әйткәннәр иде. Иң башта быел 88 яшен тутырачак Зәйнәп апаны җырлатып алдык, артык ялындырып тормады – «Сарман» җырын сузып та җибәрде. Шакировлар тумышлары белән Сарман районының Яңа Буләк авылыннан. Зәйнәп апа исә бирегә килен булып төшкән. 40 ел клубта җыештыручы булып эшләгән. Авылдашлары аның җырлый-җырлый эшләргә яратуын әле хәзер дә искә алып сөйли. Авылга килгән кунакларны бәлеш пешереп сыйлый торган булган. Илһам абыйның да иң яраткан ризыгы итле бәлеш икән. Сөйләшүебез үзеннән-үзе яраткан җырчыбызга күчте.

– Илһам миннән алты яшькә кечкенә. Бала вакытыннан ук җырлый иде инде. Әткәйне 1937 елны төрмәгә утырттылар. Әни, үзен юатыпмы икән, гел җырлый иде. Аңа ияреп, Илһам да җырлый. Шушы авылда кияүдә булган бертуган Гыйльмениса апабыз килә иде безгә. Аның, булды, җырламагыз, юньлегә түгел бу, әтинең башына җитәсез, бәхетсезлек китерәсез, дип ачуланганы хәтердә. Ә алар барыбер моңланды. Әни, мескенкәем, күңеле янганга җырлагандыр инде, – дип искә ала ул.

Әтиләре Гыйльметдин авылның оста тимерчесе булган. Ындыр табагында эшләгән вакытында икмәк сугу машинасы ватыла. Төшкә кадәр аны төзәтеп куя. Әмма авыл куштаннары кызу эш өстендә «бер атна буе төзәтми ятты» дип өстеннән язалар.

– Әтине төнлә Минзәләгә алып киттеләр. Шул китүеннән без аны күрмәдек. «Халык дошманы» дип, Сталин төрмәләрендә юк ителде. 1940 елда Имаметдин абыебыз аның белән күрешеп кайтты. Шуннан соң әти турында бер хәбәребез дә булмады. Әни алты бала белән берүзе калды. Әтине алып киткәч, йорт салырга дип кайтарып куйган бүрәнәләрне дә алып китеп бетерделәр. Энебез Кыям бик булдыклы, тырыш булып үсте. Армиядән кайткач, яңа өй җиткерде. Гөлсем апабыз яшьтән торф чыгаруда булды. Гыйльмениса апабыз да бик матур җырлады. Ә Илһамыбыз үзе җырларга яратса да, беркайчан да, җырчы булам, димәде. Беренче сыйныфка укырга кергәннән алып бер концерт та аннан башка узмады. Чыршы тирәли җырлап кына түгел, биеп йөргәне дә хәтердә. Җырлый башласа, авыл карчыклары туктый алмый елый иде. Күрше Чыршылы авылында укый башлагач та сигез чакрым араны барганда да, кайтканда да җырлап йөрде. Ул Казанга укырга киткәч, өйдәгеләр барыбыз бер сүздә булып: «Җырлап тамак туймый, берәр эшкә кер», – дип кат-кат әйтә идек. Әнкәй дә: «Көне-төне юлда йөрисең, болай яшәп булмый», – дип гел әйткәләде. Әни үлгән көнне дә ул төнлә Украинага китәргә, анда концерт куярга тиеш булган. Аңа тиз генә телеграмма суктылар. Самолет белән кайтып төште. Әнкәйне күмгәч, тагын аэропортка чыгып китте. Аны озатканда сөйләшкән сүзләребез бүген дә истә. «Мин шушы көнгә кадәр бәхетле булганмын, ә хәзер тома ятим калдым», – диде Илһам. Син генә түгел, бөтенебез дә ятим калдык, дигәнемә, ул: «Апа, синең ирең, балаларың бар, ә минем беркемем дә юк», – диде. Өйләндеребез соң сине дә, дигәч, минем гаилә корырга вакыт юк, булмас та инде, дип куйды. Әнкәй исән чакта Илһамга кунакка барып тора иде, аның ялгыз булуына бик борчылды, – дип сөйли Зәйнәп апа.

Зәйнәп апа Илһам абый белән еш күрешеп тора икән.

